Юл өчен көрәш

Яңа күршеләре килгәннән бирле, Поляковлар гаиләсе өчен бакча баш бәласенә әйләнгән. Бакчага керә торган юлны күршеләре рәшәткә белән әйләндереп алган. Хәзер Поляковлар үз участокларына урман буендагы сукмактан йә икенче бер күршесенең бакчасы аша йөрергә мәҗбүр.

5 БИТ

Туган ил тик бер генә...

Марат Кәбиров: «Җиңү бәйрәме тираҗларында патриотизм турында искә төшерәләр. Бу тантана кешеләр күңелендә Ватаныбыз өчен горурлык хисләре уятырга тиеш кебек тоела. Ләкин карашлар бер генә төрле түгел икән. Мин дә шул хакта сүз куертып алырга булдым. Ошамаса, укып тормагыз. Килешмәсәгез, мин ялгышкан диеп уйлагыз».

6 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Пәнҗешәмбе | 11.05.2017 | № 49 (5811)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

КАЗАН БАЗАРЛАРЫ

Үзәк (Колхоз) базар, Вьетнам, Порт һәм Тура базарлары: товар һәм бәяләр, уңайлылык һәм транспорт чишелешләре, кайсы районга нинди базар якынрак – «Шәһри Казан» журналистлары башкаланың иң зур дүрт базарын йөреп чыкты.

8-9 БИТ

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

П2430 Атналык (пәнҗешәмбе)

1 айга 69 сум 31 тиен

3 айга 207 сум 93 тиен

6 айга 415 сум 86 тиен

Ташламалы бәядән язылу!

11-21 май, 2017

Абунәче декадасы

П2395 Көндәлек (сишәмбе, пәнҗешәмбе, җомга)

142 сум 38 тиен 1 айга

427 сум 14 тиен 3 айга

854 сум 28 тиен 6 айга

Реклама

РЕСПУБЛИКАДА

ЧИРМЕШӘН

Әмир авылында «Авыл көне» быел да үтәчәк. Сабан туе форматында булачак әлеге бәйрәм 22 июльгә билгеләнгән. Аны шушы авыл егетләре – Сургутта эш йөртүче Миндар һәм Фазыйл Әгъләмовлар инде бишенче тапкыр оештырмакчылар.

ӘЛМӘТ

Чаллыда узган «Бриллиант кәләш – 2017» Бөтенроссия конкурсында Әлмәттән хирург-табибә Ләйсән Нәбиуллина, беренче урынны яулап, Татарстанның бриллиант кәләше дип табылды. 15 майда ул Пермь шәһәрендә үтәчәк Россия финалында Татарстан данын яклаячак.

БИЕКТАУ

13 май көнне Шәпше авылында «Иске Казан түгәрәк уены» татар фольклоры республика фестиваленең финал концерты узачак. Фестивальдә 400дән артык артист катнашачак. Конкурс быел җиде номинациядә үтә. Шулай ук «Такмак әйтеш» ярышы да уздырылачак.

ӘЛКИ

Татарстан мәктәпләре арасында «Уңышлы мәктәп» конкурсы үткәрелде һәм аның нәтиҗәләре чыгарылды. Базарлы Матак мәктәбе әлеге конкурста җиңүче дип табылды – аңа 1 миллион сумлык грант бирелә.

КАМА ТАМАГЫ

Кама Тамагы Туган якны өйрәнү музеенда Бөек Җиңүнең 72 еллыгына багышланган «Хәтер эзләреннән» дигән яңа күргәзмә оештырылды. Анда Хәтер китабы, ретро-открыткалар, пилотка, котелок, каскалар, юбилей фотоальбомнары урын алган.

ЯШЕЛ ҮЗӘН

Яшел Үзәндә икенче тапкыр этләр күргәзмәсе оештырылган. Мондый дәрәҗәдәге ярыш Россиядә дүртенче тапкыр уза. Мәскәүдән, Төмәннән, Уралдан килүчеләр бар, барлыгы – 142 катнашучы.

СПАС

«Уылдык» операциясе кысаларында, районның хокук саклау органы хезмәткәрләре браконьерлык белән шөгыльләнгән өч кешене тотты. Дәүләт автоинспекциясе хезмәткәрләре туктаткан машинада барлыгы 17 мең сумлык балык була. Ширбәт авылы янында исә оперативниклар аларны балыкны машинага төягәндә тоталар.

Яңалыклар район газеталары сайтларыннан алынды

Татарстанда кош гриппы: 447 мең тавыкны юк итәчәкләр

«Май безнең өчен уңышлы килмәде», – ди Татарстан Баш дәүләт ветеринария инспекторы Алмаз Хисаметдинов. 21 апрельдә Ростов өлкәсеннән кергән күркә итендә кош гриппы ачыкланган булган. Бу продукция безнең республикада 326 тонна исәпләнә. Хәзерге вакытта Россельхознадзор идарәсе күркә партияләрен тикшерә.

Кош гриппы белән авырган тавык күкәен ашадым, дип шикләнгән кешеләргә Татарстанның баш дәүләт ветеринария инспекторы Алмаз Хисаметдинов артык борчылмаска киңәш итә. «Әгәр моңа кадәр авырмагансыз икән, димәк, бар да яхшы, – ди ул. – 70 градус эсседә вирус үлә. Әкүкәйне пешермичә берәү дә ашамый торгандыр». Сораулар туса, Татарстан буенча Россельхознадзор идарәсенең Дәүләт ветеринар күзәтчелеге бүлегенең «кайнар элемтә» телефонына ***(843) 278-93-53, 277-65-14*** *номерлары аша шалтыратырга мөмкин.*

Бу эш буенча нәтиҗәләр чыгарырга да өлгермәделәр, тагын бер яңалык – 7 май көнне Лаеш кошчылык комплексында H5штаммлы вирус табылган. Әлегә кош гриппының комплекска ничек үтеп кергәнлеге билгесез. Бәлки кыргый күчмә кошлар йоктыргандыр, кошлар өчен кайтартыла торган азык-төлек аша күчкәндер, кеше факторы да роль уйнарга мөмкин дип фаразлыйлар. Ничек кенә булмасын, 15 меңгә якын тавык инде үлгән. Аларны яндыралар. Якын арада Лаеш кошчылык комплексында булган барлык 447 мең баш тавыкны да юк итәчәкләр. Аннары чистарту эшләре вакытында карантин игълан ителәчәк. Комплекста эшләүчеләргә вирус иярмәсен өчен дә барлык саклык чаралары күрелә.

– Лаеш кошчылык комплексы җитештергән товар базарда 10 процентны гына тәшкил итә. Шуңа да бу вакыйга күкәй бәяләренә тәэсир итәр дип уйламыйм. Хуҗалык үзе кызганыч. Комплекска 100 миллион сумлык зыян киләчәк. Аларга, мөмкинлектән чыгып, ярдәм кулы сузарбыз дип уйлыйм, – диде Татарстанның авыл хуҗалыгы министры Марат Әхмәтов.

«Лаеш кошчылык комплексы» товарын «Деревенька» исеме белән чыгара иде. Май аенда алар җитештергән 1 миллионга якын данә күкәй сатуга чыгарылган. Аларның 300 меңе кибет киштәләреннән алынган. 214 меңе балалар туклануы өчен каралган булган. Ул партия дә тикшерелә.

«Деревенька» күкәйләрен алган кешеләргә Россельхознадзор идарәсе тәүлек буе эшли торган лабораториягә мөрәҗәгать итәргә киңәш итә. H5штаммлы вирусның кешегә ни дәрәҗәдә зыянлы икәнен әлегә төгәл генә әйтеп булмый. Владимирдагы Бөтенроссия терлекчелек фәнни-тикшеренү институты уздырган лаборатор тикшерүләр нәтиҗәләре ачыклангач, бу хакта төгәлрәк әйтеп булачак.

Россельхознадзор идарәсе Лаештагы кошчылык комплексын соңгы тапкыр өч ел элек тикшергән булган. Быелның 16 мартыннан кергән карар нигезендә, хәзер кош үрчетүче фабрикаларны ешрак тикшерергә дә мөмкинлек бирелгән. Хәер, бу вакыйгадан соң болай да тикшерүләр булмый калмас. Лаеш кошчылык комплексыннан ун чакрым зонада урнашкан шәхси хуҗалыктагы тавыкларны тикшерә башлаганнар инде. Кабат кош гриппы ачыкланмаган.

Эльвира МОЗАФФАР.

Шәһәр кәефе

РАХМАН ШӘФИГУЛЛИН,
мөхәррир:

– Балык Бистәсе районының Югары Тегермәнлек авылыннан бабай Шәфигулла Вәлиев 1914 елдагы Герман сугышында катнашкан, Георгиев кресты белән бүләкләнгән. Әтием Галимулла Бөек Ватан сугышына 1941 елда алынган. Ул сугыштан икенче төркем инвалид булып кайта. Казанда бабай белән әтинең фоторәсемнәрен күтәреп, «Үлемсез полк» йөрешендә катнаштым. Үзем дә отставкадагы капитан. Күңелемдә бүген дә хисләр таша.

АЙГӨЛ ӘХМӘТГАЛИЕВА,
язучы:

– Казаныбыз – олуг шәһәр. Урам юлларында транспорт чараларын идарә итүчеләрнең бер-берсенә һәм җәяүлеләргә битарафлыгы Казанның дәрәҗәсен төшерә. Юл кагыйдәләрен тупас бозганнарга штрафны да «бик тупас» зурлыкта салырга кирәк, минемчә. Икенче мәртәбә уйланырлык булсын. Актанышка әти-әнием янына кайтып йөрибез. Артыгын хыялланмыйм, саулык кирәк. Туганнарыбызның, саулыкның кадерен белик.

ЛЮБОВЬ ТАМБОВЦЕВА,
пенсионер:

– Казанда туып-үстем. Авиация төзелешендә хезмәт куйдым. Хәзер хезмәт урыныбыз бакча кишәрлегендә инде. Җәй буе яшелчәләр, чәчәкләр үстереп мәш килә. Яз җитте, дип сөенеп йөри идем инде. Күңел бакчага, табигатькә ашкына. Озын кышлар ялыктырган иде, һава тагын салкынайтып җибәрде. Тәрәзә төбендәге үсентеләрне, түзеге инде бераз, дип юатып йөрим. Җәйне, җылылыкны, бакчаны бик сагындым. Бакчада яшәреп киткәндәй булам.

ГӨЛСӘРИЯ САБИРОВА,
пенсионер:

– Казанга 1960 елда Арчадан килдем. Күп еллар төзелештә эшләдем. «Дружба» кинотеатрын, 15нче хастаханәне безнең 2нче трест төзеде. Бригада кызларын еш искә төшерәм. Шаяра-көлә эшләгән чаклар бар иде. Гомер күз ачып йомганчы уза. Элеккеге бригадабыздан икесе фани дөньядан китеп барды инде. Арчага зиратка кайтып килдек әле шушы арада гына. Үлгәннәрне дә онытмыйк. Дөньялар имин булсын! Яшьләргә бездән хәер-фатиха.

ХАРИС БАРИЕВ,
пенсионер:

– Мин җиде айлык вакытта әтием Барый белән әнием Әминә Әтнәдән Казанга күченеп килгәннәр, үзем 1933 елгы. Әти сугышка киткәндә, без дүрт бала калган, әни еш авырый иде. Мин – иң «зурысы», шунлыктан кече туганнарыма әти дә, әни дә булырга туры килде. Сугыш елларындагы ачлык-ялангачлык искә төшкәндә, хәзер дә сулышлар кысылып куя. Бүгенге тормышыбыз Аллага шөкер!

udm.net

Чәчү 20 майга төгәлләнәчәк

Татарстанда язгы чәчү эшләре экватор сызыгын узган. 576 мең гектар мәйданда уҗым утыртылган. «Яңгырлы көннәр эшне тоткарласа да, 20 майга чәчү эшләрен төгәлләрбез», – дип ышандыра Татарстанның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов. Зәй, Сарман районнарында язгы чәчү инде бу атнада ук тәмамланачак.

– Кар сулары, яңгырлар, салкынча көннәр туфракта җитәрлек дым тупларга ярдәм итте. Әмма уҗым культураларыннан рекордлы уңыш көтмибез. Аларның, былтыргы белән чагыштырганда, потенциалы начаррак, – ди министр.

Язгы чәчү компаниясе 22 миллиард сумга төшә. Монда ашламалар, тукландыру, техника белән тәэмин итү, орлык бәясе дә кергән. Быел шикәр чөгендере, көнбагыш мәйданнарын арттырырга җыеналар. Марат Әхмәтов әйтүенчә, бу төр үсемлекләр үзләрен корылыкка чыдам буларак күрсәтә алган.

Орлыклар да сыйфаты буенча былтыргыдан яхшырак, запас күләме 13 процент тәшкил итә. Чәчү эшендә 11 меңнән артык трактор катнаша. Бүген дизель ягулыгы бәясе шактыйга кыйммәтләнгән – 37 сумны тәшкил итә. Әмма авыл хуҗалыгы өлкәсе аны ташламалы бәядән алу җаен тапкан. Ягулыкны 33, 5 сумнан алалар.

– Язгы чәчү эшләрен вакытында төгәлләү мөһим. Үсентеләр май кояшын күреп калырга тиеш, – ди Марат Әхмәтов.

Майның уртасына да җиттек, ә суыклар китәргә ашыкмый. Балтач районы Яңгул авылында яшәүче «халык синоптигы» Әмир абый Шәрәфиевкә шалтыратып, суыкның кайчан бетәчәген сораштык. Ә ул әле китәргә ашыкмый икән, ул гына да түгел, июнь дә салкынча булачак.

Суыклар сузыла әле

– 7 февральдән 19 мартка кадәр «хут суыгы» булырга тиеш иде. Гыйнвар азагыннан март башына кадәр була торган салкыннарны татарларда «хут суыгы» дип әйтәләр. Бу вакытта иртән һәм кичен – салкын, көндез җылы була. Шушы чорда булырга тиешле салкыннар апрель белән майга калды. Февраль белән март җылы булды, хәтта кара каргалар ике атнага иртәрәк килде. Тагын бер сынамыш суыкларның тоткарланачагын әйтә. Пасхада суык булса, ул 40 көн дәвам итәчәк. Христианнарның сынамышлары шулай ук бик еш туры килә. Быел Пасха 16 апрельдә булды. Ул көнне салкын иде. Димәк, май ахырына кадәр көннәр җылылыгы белән әллә ни сөендермәячәк. Ике-өч көн җылы булып, тагын суытып алачак. Мондый очраклар сирәк була. Бу салкыннарны бездә шомырт суыклары дип тә әйтәләр. Әле май ахырында балан суыгы да булачак. Тагын ике тапкыр кырау төшәчәк. Июнь дә салкынча киләчәк, – дип сөйләде ул безгә.

Алдагы көннәрдә һава торышында әллә ни үзгәреш юк. Көндез – 6-8 градус, төннәрен 1-2 градус җылы булачак. Явым-төшемнәр дә булыр дип көтелә.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА.

Менә бу тизлек!

Татарстан матбугаты көне якынлашканда, шуны уйлыйм әле: көндәлек газетаның әйбәтлеген күпторле билгеләр аша танып була икән бит. Өйгә килә торган «Шәһри Казан»ның шундый бер билгесенә күптән игътибар иткәнем бар. Әйтик, Казандагы яки Татарстандагы берәр вакыйганы яисә берәр яңалыкны телевизордамы, радиодамы аз-маз ишетеп калдың, ди. Шул хакта күбрәкне белергә, төплерәк мәгълүмат алырга теләсәң, нишлисең инде? Икенче көнне хат ташучы өеңә китергән газетага «капланып», теге вакыйга турында язма эзләргә керешәсең! һәм, әгәр кулыңдагы газетаң «ШК» атлы булса, син өметләнеп көткән мәкаләне һичшиксез табасың. Сиңа инде «Ничек теге вакыйга урынына барып һәм шул хакта язып өлгерткәннәр болар!» дип сокланырга гына кала. Журналистлары да «азу ярган», зур исемнәр алган ниндидер атаклылар түгел ләбаса, күпчелеге гади генә, бәләкәй генә кызлар-киленнәр.

Чит хәбәрчеләрнең әйбәт дип табылган мәкаләләрен чыгаруда да «Менә бу тизлек!» дип хәйран калырлык эшли алар. Һәрхәлдә, дүшәмбе көнне электрон почта белән җибәргән, бик кечкенә булмаган язмаң сишәмбе газетасында өеңә әйләнеп кайтса, моңа гаҗәпләнәсе түгел, чөнки эшләү тәртипләре шундый аларның.

Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ,
Балтач районы, Карадуган авылы.

КҮРШЕЛӘРДӘ

Башкортстанда дәүләт-шәхси партнерлык нигезендә, өлкәннәр һәм инвалидлар өчен пансионат төзү буенча проект тормышка ашырылачак. Ул Мишкин районының Ирсай авылында барлыкка киләчәк. Әлеге проектны инвестицияләү буенча концессия килешүе Уфада имзаланган. Бу хакта «Башинформ» агентлыгы хәбәр итә. Документ шартлары буенча, концессионер тарафыннан биреләчәк инвестиция 5 миллион сумнан да ким булмаячак. Әлеге проектны тормышка ашырган очракта, 15 эш урыны һәм социаль хезмәт күрсәтелүчегә уңайлыклары белән 25 койка урыны булдырылачак.

* * *

Мари Элның башкаласы Йошкар-Олада 13 майда «Шома бас» II Халыкара бию фестиваль-бәйгесе узачак. Татар мәдәнияте үзәге сәхнәсендә чыгышлар 7-12, 13-17 яшьлекләр һәм 18 яшьтән өлкәнрәк биючеләр арасында аерым, «Халык биюе», «Халык биюен стильләштерү», «Заманча биюе», «Эстрада биюе», «Классик бию» кебек номинацияләрдә бәяләнәчәк. Узган ел беренче фестивальдә Мари Эл, Татарстан, Әзәрбайҗан, Үзбәкстан, Таҗикстаннан 30 коллектив катнашкан.

* * *

Чувашия башкаласы Чабаксарда Сабан туе 13 майда булачак. Ул, елдагыча, Лакреев урманында узар дип көтелә. Бирегә уза торган Сабан туенда елның елында татарлар гына түгел, калган милләт вәкилләре дә күңел ача.

САН

*Быел Татарстанга федераль бюджеттан социаль инфраструктура объектларын сафка бастыруга **1 млрд 791 млн сум** акча бүлеп биреләчәк.*

27 майда уразага керәбез

27 майда Рамазан аена керәчәкбез. Беренче тәравих намазы республика мәчетләрендә 26 майда укыла. 25 июньдә – Гает көне. Татарстан мөселманнарының чираттагы пленум утырышында быел фидия сәдакасын 200 сум дип билгеләделәр. Зәкят түләү өчен нисаб күләме – 198 000 сум. Фитыр сәдакасы – 100 сум.

ТОП – 3

2018 ЕЛДА Россиядә әдәбият буенча Бердәм дәүләт имтиханының яңа моделе барлыкка килергә мөмкин. Ул имтиханны эчтәлеге ягыннан яхшыртуга юнәлтелгән. Имтиханнан кыска җаваплар белән булган биремнәр алынган, укучылар җавабын сайлап ала торган биремнәр арткан, инша күләменә таләпләр үскән.

РОССИЯДӘ пенсия яшен озайтырга мөмкиннәр. 2019 елдан башлап, пенсия яшен хатын-кызларга – 63, ир-атларга 65 яшькә кадәр озайту тәкъдим ителә. Әлеге чара Россиядә пенсионерлар санын якынча 4 млн кешегә (9 процентка) – якынча 38,52 млн кеше калырлык итеп киметергә мөмкинлек бирәчәк.

ГАЛИМНӘР, экология һәлакәте булмасын өчен, Арктика бозларын ясалма юл белән туңдырырга тели, дип хәбәр итә «Татар-информ». Диңгез суын батмый торган калкавычларга – махсус буйларга тутыра һәм аннан соң боз өстенә шул суны сиптерә торган ун миллион җил тегермәне урнаштырырга тәкъдим ителә. Шул рәвешле кабаттан боз туңуга һәм экология һәлакәтен булдырмый калуга ирешергә мөмкин. Шулай ук, җылынуны туктатмаган очракта, 2030 елга барлык диңгез бозы эреп бетәргә мөмкин, дип раслый галимнәр.

Вячеслав ОРИНОВ,
Чувашия Республикасы мәдәният министры урынбасары:

Мин – чуваш, татарча өйрәнергә телим. Һәрбер халыкның теле матур.Ә сез аны бик яхшы саклагансыз. Без, төрки дөнья вәкилләре, бер-беребезне хөрмәт итәргә һәм яратырга тиеш.

(«Урмай зәлидә» халыкара фестивале ачылышында әйткән сүзләре)

ГАҖӘП

Индонезиянең Ява утравында дөньяның иң озын гомерле кешесе вафат булган, дип хәбәр итә Ислам ру. Содимеджо исемле ир-атка 146 яшь булган. Ул 1870 елның 31 декабрендә туган. Авылдашлары Содимеджоны «Гото бабай» дип йөрткән. Аның ун абый-энесе, дүрт хатыны һәм балалары күптән вафат икән инде.

МАГНИТ ДАВЫЛЛАРЫ

11-17 майда магнит давыллары көтелә. Метеосизгерлеге югары булган кешеләр бу көннәрдә озак вакытка сузылган көчле баш авыртулардан, кан басымы уйнавыннан, йокысызлыктан, буыннар һәм мускуллар авыртуыннан, эч пошудан зарланырга мөмкин.

Игътибар иткәнегез бармы, Җиңү көнендә, күк нинди аяз булуга карамастан, аз гына булса да яңгыр яумыйча калганы юк. Быел да табигать сыкранды. Әйтерсең ул сугышта һәлак булган солдатларның, улсыз калган аналарның, атасыз калган балаларның кайгысын урталаша. Ләкин сибәләп торган яңгыр да, күкне тырмап йөргән кургаш болытлар да бу көнне халыкны куркытмады. Алар тыныч тормыш бүләк иткән бабаларының якты истәлеге хакына урамга чыкты.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

КҮЗ ЯШЬЛЕ БӘЙРӘМ

Алисә САБИРОВА

«КАҺАРМАННАРЫБЫЗНЫҢ ОНЫТЫЛУЫНА ЮЛ КУЙМЫЙБЫЗ»

Һәр нәрсә Җиңү көнен искәртә иде. Хәтта Казанда 9 Май бәйрәме дә Җиңү паркыннан башланды. Ә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов, Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, республикада бердәнбер исән калган Советлар Союзы Герое Борис Кузнецов паркка «Победа» автомобилендә килде. Алар Мәңгелек ут белән Аналар һәм тол хатыннар һәйкәленә чәчәкләр салды.

Паркта олылар һәм урта буыннан тыш, балалар күп булуы да куанычлы күренеш иде. Нарасыйлар әтиләренең иңбашларына утырып бәйрәм күзәтергә, шул ук вакытта паркта урнашкан хәрби техника турында сорашырга да өлгерде. Ә кыюраклары, йөгереп килеп, ветераннар кулына кызыл канәфер сузды.

Үзе хәрби булган Евгений Яухин да бәйрәмгә оныгы белән килгән. Аныңча, канкойгыч сугыш хәтерен яшь буынга җиткерү чарасы бу.

– Мин Белоруссиядә үстем. Анда сугыш эзләре калган иде әле. Шуңа да бу сугыш минем дә бала йөрәгемне өтте. Бер елны да Җиңү көнендә өйдә утырганым, Җиңү парадын карамыйча калганым юк. Барлык хәрби дусларым да бирегә килә, – диде ул.

Бәйрәмнең төп чаралары Меңьеллык мәйданында узды. Парад театральләштерелгән тамаша белән башланып китте. Хәрби оркестрның Преображение полкы маршы башкаруында мәйданга Россия белән Татарстан флагын чыгардылар. Тамашачылар аны аягүрә басып каршы алды. Мәскәү белән турыдан-туры элемтә вакытында Россия Президенты Владимир Путин: «Безнең халыкны җиңә алырдай көч булмады һәм булмаячак», – диде. Бер минут тынлыктан соң республика халкын бәйрәм белән Рөстәм Миңнеханов котлады.

– Җиңү бәйрәме – күпмилләтле халкыбызга дан, бердәмлек һәм батырлык көне. Безнең ил нацизмның тамырын юк итте, Европаны коллыктан азат итте, миллионлаган кеше хисабына фашизмны җиңүгә иреште. Яу кырларыннан әйләнеп кайтмаган батырларга һәм инде хәзер безнең арада булмаганнарга мәңгелек Дан! Хөрмәтле сугыш һәм тыл хезмәтчәннәре, бүгенге имин тормыш өчен без сезгә рәхмәтле. Безнең бурыч – сез калдырган хәтерне киләчәк буынга тапшыру. Каһарманнарыбызның онытылуына юл куймаячакбыз, – диде Татарстан Президенты.

Казан хәрби гарнизоны җитәкчесе, генерал-майор Кирилл Кулаков һәр парад расчетын (алар барлыгы 26 иде) бәйрәм белән котлады. Алар исә үз чиратында генералны: «Ура!» – дип сәламләде. Парадта 2 меңгә якын кеше катнашты: араларында суворовчылар, кадетлар, курсантлар, офицерлар, Казан танк училищесы студентлары, Казан юридик институты студентлары, Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре, юнармеецлар, Әфган сугышы ветераннары да бар иде.

Меңьеллык мәйданы буйлап «БТР», «КАМАЗ», броньле автомобильләрдән торган 14 берәмлек хәрби техника да узды. Ахырдан тамашачылар «ГАЗ-М1», «Победа», «Волга», «ГАЗ-21» кебек ретро автомобильләрне дә күрә алды. Парад карарга килгән кешеләр Казан Кремле тирәсен, Үзәк стадион мәйданын, «Пирамида» мәдәни-күңел ачу үзәге территориясен дә сырып алган иде.

ФОТОСУРӘТЛӘРДӘ – СУГЫШ ХӘТЕРЕ

Көндезге 3ләр тирәсендә Казанның үзәк урамнары буйлап «Үлемсез полк» үтте. 120 меңгә якын кеше сугышта катнашкан һәм тыл хезмәтчәннәренең фотолары куелган транспарантлар белән Карл Маркс, Лобачевский һәм Кремль урамнары буйлап узды. Полк йөрешендә Рөстәм Миңнеханов та катнашты. Ул, узган елдагы кебек, атасы ягыннан абыйсы – Миңнеханов Галимҗан Миңнехан улы фотосурәтен тотып барды. Галимҗан Миңнеханов 19 яшендә фронтка китә, 359нчы ату полкы составында бәрелешләрдә катнаша. 1941 елның 15 декабрендә көчле сугыш нәтиҗәсендә һәлак була.

«Үлемсез полк»та якыннары фотосурәте белән атлау өчен, халык инде көндезге берләр тирәсендә җыела башлаган иде. Биредә – һәркемнең үз тарихы. Кырымда туып-үскән Владимир Зыгарь бүген әтисе һәм бабасы фотосурәтен алып килгән. Владимир өчен бу үзгә бәйрәм, ул үзе дә Казан танк училищесын тәмамлап, озак еллар хәрби хезмәттә булган. Подполковник дәрәҗәсенә кадәр күтәрелгән. Җиңү көне аның өчен изге бәйрәм.

– Әти Бөек Ватан сугышы вакытында Севастополь шәһәрен яклаган. Бабамны 1943 елның 23 февралендә атып үтергәннәр. Аны полиция хезмәткәрләре фашистларга саткан. Сугыштан кайткач, әти, шул сатлыкҗанны табып, үч алмакчы булган. Ләкин балалары ялваргannan соң, кызганып, аңа тимәгән. «Үлемсез полк» – һәркемнең хәтере ул. Аны сакларга кирәк. Бүген без сакласак, иртәгә башка буыннарга күчә ул, – ди Владимир.

Әтисе һәм бабасы турында искә алганда, аның күзләре яшь белән тулган иде.

Ләлә Мусина акциягә тормыш иптәше һәм кызы белән килгән. Транспарантта – бабасының соңгы фотосы.

– Бабам Гомәр Гобәйдуллин сугышның беренче көннәреннән үк фронтка киткән. Ленинград якларында хезмәт иткән. Шунда ук яраланып, гангренадан үлгән. Ул вакытта аның кызы – минем әнигә нибары җиде яшь булган. Бүгенге көндә кабере дә билгесез. Аның турындагы мәгълүматны «Хәтер китабы»ннан табып белдек. Бу акцияне уйлап тапкан барлык кешегә дә рәхмәтемне җиткерәсем килә. Тиздән сугышта катнашкан ветераннарыбызның берсе дә исән калмаска мөмкин, ләкин бу акция аларны чыннан да үлемсез итә, – ди Ләлә.

73 яшьлек Фәния Шәяхмәтова бу көнне ике ел бүе көткән. Узган ел, авыру сәбәпле, полкта катнаша алмаган, быел исә ничек тә чыгам, дигән. Сугыш аның ике бертуган абыйсын тартып алган.

– Абыйларым Нури белән Мәхмүт Вәлиевләр сугышка киткәндә мин әле туган гына булганмын. Нури абый 18 яшендә сугышта хәбәрсез югалды. Аның каберен Ростов өлкәсендә 2014 елда гына таптык. 21 яшендә сугышка киткән олы абый Калуга якларында үлеп калды. Бүген тугыз баладан исәне бер мин. Абыйларымның фотосурәтен истәлек итеп өй түрендә тотам. Бик матур, яшь вакытларында үлделәр бит. Сугыштан кайткаnnar бер хәл, ә менә чит җирдә ятып калганнар аеруча кызганыч. Туганыңның кабере кайда икәнен белмәүдән дә авыррак нәрсә бар икән? – дип, күз яшьләренә буыла-буыла сөйли Фәния ханым.

Татарстаннан яу кырына 700 меңнән артык кеше китеп, шуның яртысы әйләнеп кайтмаган. Бу полк аларның истәлегенә Дан булып яңгырады.

Бәйрәм чаралары кичкә кадәр барды. Җиңү көне салют белән тәмамланды.

«ШӘҺРИ КАЗАН» ТЫҢЛЫЙ

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

ЮЛ ӨЧЕН КӨРӘШ

Яңа күршеләре килгәннән бирле, Поляковлар гаиләсе өчен бакча баш бәласенә әйләнгән. Бакчага керә торган юлны күршеләре рәшәткә белән әйләндереп алган. Хәзер Поляковлар үз участокларына урман буендагы сукмактан йә икенче бер күршесенең бакчасы аша йөрергә мәҗбүр.

Эльвира МОЗАФФАР

БАКЧА – БАШ АВЫРТУЫМЫ, ЮАНЫЧМЫ?

– Тагын җәем суд юлын таптап узармы икән инде, шундый туйдым, валлаһи, – дип, редакциябезгә килеп керде Иван Михайлович Поляков.

Үзе рус кешесе булса да, татарча яхшы аңлый, сөйләшә, хатыны Нәҗия апа да газетабызны яратып укый.

Иван Поляков – 76 яшендә, пенсионер. Озак еллар нәшриятта исәпләү техникасын ремонтлау белән шөгыльләнгән. Журналистлар һәм язучылар җәмгыятеннән аңа Югары Ослан районындагы «Аланлык» бакчачылар ширкәтеннән алты сотый җир булеп биргәннәр. Бакча табигатьнең матур урынында урнашса да, анда бары бер дә җайлы түгел. Казаннан бирегә Биектауга бара торган автобуста йә электричкада киләләр. Станциядән соң урман эченнән биш чакрымлап җәяү барырга кирәк. Бакчачылык ширкәтендә элек су булмаган. Яңа рәис Люция Шиһапова биш еллар элек скважина казыткан. Бакча кишәрлекләренә торбалар сузганнар. Су хәзер краннан ага. Артезиан суын күпләр эчәргә кыймый. «Сары төстә юшкын утыра, шуңа да эчәргә суны Казаннан шешәләр белән ташыйбыз», – диләр. Ничек кенә булмасын, һәркемгә үз бакчасы якын. Иван абзый да биредә үзенә юаныч таба. Яшелчә үстерә, ике катлы җәйге йорты, мунчасы бар. Күршесе Мансур белән балыкка йөриләр. Кышын да чаңгыда бакчасын урап кайта.

Мәшәкатьләр 2011 елда 10нчы участок хуҗасы үзенең җирен икенче берәүгә саткач башлана. 2015 елда яңа хуҗа – Сергей Зилаев – бакчасын челтәрле тимер рәшәткә белән әйләндереп ала.

– Үз кишәрлегенә күршебез бакчама илтә торган аллеяны да керткән. Кеше йөри торган юлны үзенә алган. Ә менә элекке хуҗаның кишәрлегеннән 4 метр киңлектәге, 14 метр 70 сантиметр озынлыктагы мәйданны ни өчендер алмый калдырган, – дип аптырый Иван абзый.

Без дә «Аланлык» бакча ширкәтендә булдык. Зилаевның, Поляковның бакча кишәрлекләрен карап, күзәтеп чыктык. Чынлап та, Сергей Зилаев бакчаның бер өлешен аерып калдырган. Хәтта элеккеге хуҗа Әсгать абый утырткан карлыганнар да рәшәткәнең тышкы ягында калган. Аның каравы, аллеяга юл ябык.



Юлның рәшәткә белән бүленүе Иван Поляковка тынгылык бирми.

«ТЕЛИМ ИКӘН – САТАМ, ТЕЛИМ ИКӘН – ЙОРТ САЛАМ»

Эшнең нидә икәнен аңларга теләп, Сергей Зилаевның үзенә шалтыраттык.

Ул үзе бакчага сирәк килә. Алты ел дәвамында, кишәрлегендә рәшәткә тотуны санамаганда, берни эшләнмәгән, элекке хуҗаның җиргә сеңеп барган сарае гына кыйшаеп утыра, бакчаны чүп үләне баскан.

– Телим икән – йорт салам, телим икән – сатам. Бу – минем эш. Җир, закон нигезендә, минеке, – диде ул безгә. – Элеккеге хуҗа миңа: «Аллея булган урыннан ун капчык бәрәңге ала идем», – дип сөйләде. Кемдер аны аллеяга әйләндергән дә, хәзер мине юлны яулап алуда гаеплиләр. Минем барлык документларым да кулымда. Кадастр планы буенча да барысы да законлы, – ди ул.

«Ут-күз була калса, Поляковлар бакчасына узып булмый лабаса, мондый очракта нишләргә?» дигән соравыма, Зилаев: «Юл җитәрлек анда», – дип җавап кайтарды.

Иван абзыйның бакчасына дүрт яклап керергә тырышсак та, машина юлын таба алмадык. Бер якта – урман, икенче якта – чокыр, аннан елга ага, өченче яктан аллеяны тимер рәшәткә белән күрше ябып куйган. Дүртенче якта – кеше бакчасы. Иван абзый хәзер нәкъ менә шул 8нче участок аша үз кишәрлегенә кереп йөрергә мәҗбүр.

Поляковның бакчадагы йортының техник паспорты буенча да аллея күрсәтелгән. Бакчачылык ширкәтенең спутник планын карасаң да, 10нчы, 9нчы, 7нче участоклар аша 1нче аллея уза.

Биектау районындагы Гадәттән тыш хәлләр идарәсе хезмәткәрләре бу мәсьәләне тикшергән.

– Поляков яшәгән 7нче участокка иң якын аллеяга кадәр ара 50 метрдан күбрәк. Янгын куркынычсызлыгы таләпләре буенча (п. 8.17 СП 4.13130.2013), янгын сүндерү машиналарына аз катлы (өч катка кадәр) торак корылмаларга кимендә 50 метр аралыкка кадәр якынаю мөмкинлеге тудырылырга тиеш. 8.18 пункты буенча, бакчачылык ширкәтләрендә янгын сүндерү техникасы өчен машина йөри торган төп урамнарның киңлеге 7 метрдан да таррак булмаска, ә тыкрыклар кимендә 3,5 метр киңлектә булырга тиеш. «Аланлык» бакчачылык ширкәтендәге 7нче кишәрлеккә янгын сүндерү машиналары керә алмый, – дип нәтиҗә чыгарган Россиянең Гадәттән тыш хәлләр һәм гражданнарны саклау министрлыгының Татарстан идарәсендә эшкә эшләр майоры Егор Аликов.

Бакчада өлкән яшьтәге пенсионерлар шактый. «Ашыгыч ярдәм» хезмәтенең дә кирәк булуы ихтимал, Алла сакласын. Тик хәзер 7нче участокка бер машина да керә алмый.

Иван Поляков, гаделлек эзләп, күршесен судка биргән. Биектау районында хөкемдар Наил Таҗиев аңлатканча, әлегә эш ахырына кадәр тикшерелмәгән. Эшне дәвам итү өчен, кабат дәгъва гаризасы язарга кирәк. Бер утырышта судья ике якны татулашырга да чакырган булган. Ул чакта Зилаев аллея турысына капка куярга ризалашкан. Әмма бу Иван абзыйны канәгатьләндерми.

– Җирне башка берәүгә сатса, яңа хуҗа тагын аллеяны ябып куйса? Кирәк түгел капкасы, аллеяны ачсын. Закон нигезендә, анда юл булырга тиеш, – ди укучыбыз.

Биш операция кичергән, суд юлын таптап сәламәтлеге шактый какшаган Иван Поляков гаделлек эзләвен дәвам итә. Безнең ярдәм белән, ул Татарстан прокуратурасына да шикаятьләр юллады. Хәзер киләсе судны көтә. Аллея өчен көрәш ниләр белән бетәр? Нәтиҗәләрен газетабызның киләсе саннарында язарбыз.

ТУГАН ИЛ ТИК БЕР ГЕНӘ...

Җиңү бәйрәме тирәләрендә патриотизм турында искә төшерәләр. Бу тантана кешеләр күңелендә ватаныбыз өчен горурлык хисләре уятырга тиеш кебек тоела. Ләкин карашлар бер генә төрле түгел икән. Мин дә шул хакта сүз куертып алырга булдым. Ошамаса, укып тормагыз. Килешмәсәгез, мин ялгышкан диеп уйлагыз.

ФИКЕР

Марат КӘБИРОВ

Патриотизм төшенчәсе, нигездә, шәхес һәм дәүләт мөнәсәбәтен, төгәлрәк әйткәндә, шәхеснең дәүләт өчен үзен яки үз мәнфәгатьләрен корбан итү мөмкинлеген күз уңында тота. Бу мәсьәләдә бетмәс бәхәс тудыручы нәрсә: шәхес Ватан турында күбрәк хәстәрлек күрергә тиешме, әллә Ватан шәхес турындамы?

Асылда, бу бәхәсле нәрсә түгел, һәр ике якның хәстәрлеге тигез булырга тиеш. Чөнки дәүләт гражданнардан тора, халкы ярлы һәм бәхетсез булса, ул беркайчан да бай да, бәхетле дә була алмый. Халкы турында хәстәрлек күрмәгән дәүләт, иртәме-соңмы, таркала, чөнки ул беркемгә дә кадерле түгел, аны берәү дә яклашырга теләми. Шул ук вакытта әгәр гражданнар үз дәүләте турында кайгыртмый икән, аның бәхете өчен кайбер нәрсәләрдән баш тартмый икән, бу дәүләт көчле була алмый, һәм шул хәлсез дәүләт эчендә яшәгән кешеләр дә мул, рәхәт, бәхетле тормышта яши алмый. Шул рәвешле, үзара хәстәрлек ике яклы һәм чагыштырмача тигез дәрәҗәдә булырга тиеш. Чөнки шәхестән башка – дәүләт, дәүләттән башка шәхес юк.

* * *

Ләкин чынбарлыкта алай җайлы килеп чыкмый. Моннан берничә ел элек кенә «патриот» сүзе мәсхәрә сыманрак яңгырый, һич югында, аны беркадәр ирония белән әйтәләр иде. Ул чорда: «Һәр кеше үзе өчен яшәргә тиеш, бай, бәхетле булырга. Шундый кешеләрдән торган ил дә бай һәм бәхетле булачак», – дигән караш өстенлек итә иде. Шуңа күрә һәркем бай һәм бәхетле булырга тырышты. Зу-ур җитәкчеләребез арасында хәтта дәүләтнең хәрби серләрен кичәге дошманнарга сатып баеган «эшлекләр» дә булды бугай. Аларга ваграк түрәләр иярде. Шул рәвешле, алар дәүләтебезнең бай һәм бәхетле шәхесләрдән торуына үз өлешләрен кертергә ашыкты. Чынлап та илне (аның серләрен, табигый байлыкларын һ.б. хәзинәләрен) сатарга мөмкинлеге булганнар ул чорда ярыйсы гына мантып китте. Без дә аларга хөрмәт белән карарга тырыштык. Чит илләрнең иң гүзәл урыннарында сатып алган виллалары, дөнья бәясе торган яхталары белән горурландык. Аларның Англиядә, Америкада һ.б. илләрдәге студент балаларының тик «бишле» билгеләренә генә укып, диплом алып исән-сау кайтканын түземсезлек белән көттек. Фәләнешәр миллион доллар түгеп балаларын башлы-күзле иткәндә, үзебез шул туйда катнашкан кебек сөендек. Үзебезнекеләр бит, файдалары бер тимәсә бер тияргә мөмкин. «Үзләренә җиткәч, бәлки, ил халкына да аз гына өлеш чыгарырлар әле», – дигән өмет тә юк түгел иде. Җитмәде, туя белмәделәр.

Менә шул дәверләрдә «идиот» һәм «патриот» сүзләре бер үк мәгънәгә ия була башлаган иде. Без хәтта «Бөек Ватан сугышы» дию чене гаепләп, «Икенче Бөтендөнья сугышы» дип атауны таләп итә башладык. Янәсе, бернинди Ватан төшенчәсе дә булмаган анда, бөтен дөнья мужиклары җыелышып сугышканнар да Рейхстаг өстенә байрак элгәч, өйләренә кайтып киткәннәр. Ахмаграклары үлеп калган, ә тагы да сантыйраклары герой булып үлгән. Исән кайтканнарын да акыллы дип булмый, кайберләре дүрт ел буе йөреп тә бер тиен акча эшли алмый кайткан. Чын ир-егет шундый буламы инде?!. Әнә ичмасам Фәлән Фәләневич! Кабинетыннан чыкмыйча да көненә фәлән йөз мең эшли!

Хәтта кайбер даирәләрдә: «Гитлер әфәнде җиңсә, яхшырак буласы иде», – дигән фикерләр дә ишетелгәләде. Татарлар арасында да. Ул татар халкына ирек бүләк итәр, аңа дәүләт төзеп бирер иде, янәсе. (Үзләрен милләт өчен көрәшүче дип исәпләгән бәгъзе затларның сантыйлыгы каршында сокланып туймаслык дәрәҗәгә җитә. Бу аларга Ходай тарафыннан бирелгән табигый ахмаклыкмы, әллә ниндидер көчләр тарафыннан ниндидер суммага өстәп бирелгәнме – әйтә алмыйм. Ләкин ул татарларны милли мәсьәләдән читләштерүдә әйтеп бетергесез нәтиҗәләр бирә. Милләт өчен бары тик шундый ахмаклар гына «көрәшә» икән, дигән фикер тудыра. Кемдер читтән килеп милләтеңне үстерер, сиңа дәүләт төзеп бирер дип көтү – рухи гариплекнең иң кызганыч формасы. Ә Гитлер рәвешендәгеләрдән моны өмет итү... Моңа инде сүз дә табып булмый.)

Шәхесләреннән принципиальлек, ныклык таләп итсә дә, халык үзе флюгер сыманрак нәрсә, җил кайдан исә – шунда борыла торган. Бу гаҗәп тә түгелдер, аның белән идарә итү ысулларын эшкәртүче тулы бер индустрия эшли ич.

Патриотизм хисен юкка чыгарып, бар игътибарны шәхескә юнәлтү дә әллә кайдан килгән нәрсә түгел, ә бик югарыда утырган сөекле җитәкчеләребезнең җинаятьчел гамәлләрен аклау, аларны «сатлык җан» дип гаепләмәслек шартлар тудыру өчен уйлап табылган һәм халыкка сеңдерелгән саташтыру иде. Ә матди байлык туплау, яшәү шартларын яхшырту белән мәш килгән кавем үз халәтен, кайдан килеп кая барганлыгын билгеләрлек хәлдә була алмады. Әлбәттә, мөлкәт туплау, яхшырак яшәргә тырышу начар нәрсә түгел. Ләкин бу үзмаксатка әйләнә икән, кеше хайван дәрәҗәсенә төшә, ә халык кулланучылар көтүенә әверелә.

* * *

Украинада ызгышлар башланып, халыкара хәлләр кискенләшү белән, сөекле хөкүмәтебез патриотизм турында искә төшерде. Россия хөкүмәте халык турында уйласын өчен, нигәдер, дөньядагы хәлләрнең беркадәр көчергәнешле булуы таләп ителә. Бу – тарих тарафыннан исбатланган аксиома кебек.

Һәм, әлбәттә, патриотизм тәрбияләү өчен нигез булып тагын Бөек Ватан сугышы хезмәт итте. Сугыш ветераннары данга да, хөрмәткә дә лаек. Исән калганнарының кадерен белергә, мөмкин кадәр тәрбия кылырга кирәк. Бу – бәхәссез.

Ләкин ул сугышта җиңүне геройлар һәм бүген исән калган ветераннар гына яулап алмаган. Минем, мәсәлән, ике бабам да шунда һәлак булган. Һәм бу әти-әниемнең язмышын бөтенләй көтелмәгән якка, бәхетсезлек, ярлылык, ятимлек тарафына үзгәртеп җибәргән. Әбиләр яуда үлгән ирләренә тугры булып, ни ир бәхете, ни тормыш рәхәте күрә алмыйча, дөньядан китеп бардылар. Җиңү бәйрәмнәрендә дә урыннары түрдә булмады, ятлар сөйләгәнгә кул чабып утыручылар арасында булды. Һәм өйгә кайтканда: «Фәлән кешеләргә бүләкләр бирделәр, ә безнекеләрне искә алучы да юк», – дип әрнеделәр. Болар – геройлар да, орден-медальле хөрмәт ияләре дә түгел иде. Безнең илдә бабасы яки әбисе яуда катнашмаган, яки үлеп калмаган бер генә гаилә дә юк диярлек. Һәм андый гаиләләрнең берсенә дә җиңүче дәүләт әллә ни игелек күрсәтә алмады. Бер сүз белән әйткәндә, яуда үлеп калган гади солдат гаиләләренә бу Җиңү бернинди кадер-хөрмәт тә китермәде. Беркайчан да. Һәм бүген бик күп тарафлардан: «Җиңү безгә нәрсә бирде?» – дигән сораулар ишетелә икән, бу наданлык кына да, риторика гына да түгелдер. Әгәр халыкның бер өлеше шулай дип сорарга мәҗбүр икән, димәк, патриотик тәрбиянең ниндидер механизмы дөрес эшләми.

Икенче яктан карасаң, болай дип сорау – беркатлылык. Әгәр бу ил хәтта геройларын да фәкать үзенә кирәктә генә искә төшерә икән, аннан тагын нәрсә көтәсең инде?

Нәкъ менә шушы күренеш хәтта бик зурлап уздырылган җиңү тантаналарында да беркадәр киная белән карарга, моны дәүләтнең ихлас хәстәрлеге дип түгел, ә бүгенге хөкүмәтнең пиар акциясе дип бәяләргә мәҗбүр итә. Һәм патриотизм турында искә төшерүләрнең тышкы сәясәт киеренкелеге белән тәңгәл булуы бу тойгыларны тагы да куәтләп кенә җибәрә. «Безнең ил үзенең Ватан-ана икәнен хөкүмәткә авыр чакта гына искә төшерә», – дип шаяртуларның да нигезе шушында.

* * *

Ләкин патриотизм булырга тиеш. Дәүләт бар икән, ул патриотизмнан башка озак яши алмый. Патриотик тәрбия дә булырга тиеш. Һәм ул тәрбия хөкүмәттә утырган җитәкчеләрнең яшәү рәвешеннән башлана. Ватан өчен корбан булган геройларны үрнәк итеп куюдан, башкаларны шулар үрнәгендә тәрбияләргә тырышудан да түгел. Миллионнар, миллиардлар түгеп оештырылган һәм аның бик әһәмиятле икәне матбугат әһелләре тарафыннан туктаусыз рәвештә халык аңына сеңдерелгән чаралардан да түгел. Патриотик тәрбия фәкать ил җитәкчелегенең яшәү рәвешеннән башлана. Җитәкчеләр бик югарыда утырсалар да, бу – аллалар биеклеге, халык күзе җитмәслек биеклек түгел. Шулай булгач, халык барысын да күреп тора. Ул дәшмәскә мөмкин. Ләкин күрә. Һәм ышанмый. Барысы да гади генә. Әгәр дәүләт җитәкчеләре үз мөлкәтләрен чит ил банкларында саклый икән, әгәр аларның балалары чит илләрдә белем ала, эшли, яши икән... бу очракта халык фикере бер генә булырга мөмкин: димәк,безнең җитәкчеләребез үз Ватаның яратмый, аның бүгенгесенә дә, киләчәгенә дә ышанмый һәм бу илне фәкать үз мәнфәгатьләре өчен файдалана. Һәм бу фикерне бернинди тәрбияви чара да үзгәртә алмый.

Ләкин хөкүмәт үткәргән һәртөрле чаралардан башка да яши торган патриотизм да бар. Монысын алай атау дөрес тә түгелдер әле. Бу бик гади һәм гали нәрсә, бернинди «изм»нарсыз да яши ала, бернинди пропагандага да мохтаҗлыгы юк. Исеме дә гади генә – туган илгә мәхәббәт. Һәртөрле патриотизм чаралары белән йөрәкне алып бетергәч, без ул хисне байрак итеп күтәреп йөртмибез, кеше сизмәсрәк урынга яшерергә тырышабыз. Һәм ниндидер язылмаган канун буенча, ул хис кайчагында патриотизмның антонимы булып та тоела. Патриотизм – өстәгеләр тарафыннан тагыла торган ясалма нәрсә, ә туган илгә мәхәббәт һәркемнең үз йөрәгендә яралган табигый тойгы сыман була. Югыйсә, икесе дә бер үк мәгънәне аңлатырга тиеш кебек бит инде. Күрәсең, бу адәм организмының кеше белән идарә итү методикаларына каршы көрәшү ысулыдыр инде. Патриотизм булырга тиеш дигән идек. Адәмчә җәмгыятьтә ул нәкъ менә туган илгә мәхәббәт дәрәҗәсендә булырга тиеш. Кызганычка, бүгенге җәмгыятьтә бу мөмкин түгел. Без бу ике сүзне ике төшенчә итеп карарга мәҗбүр. Хәтта кайчагында хөкүмәт – бер нәрсә, дәүләт – икенче, ә туган ил бөтенләй бүтән булып тоела. Хөкүмәт ул киләдә китә, дәүләт тә әле бер, әле икенче кыяфәткә керә. Ә туган ил кала. Һәм аны яратмыйча мөмкин түгел.

«Кыстыбый» – татарча милли фаст-фуд

МИЛЛИЯТ

Кыстыбыйның ничә төрен беләсез? Ә менә яңа танышым – яшь эшмәкәр Азат Нәҗметдинов аның 16 төрен уйлап тапкан. Уйлап кына калмаган, ә «Кыстыбый» дигән заманча милли кафе да ачкан.

Алисә САБИРОВА

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

БӘРӘҢГЕ ГЕНӘ ТҮГЕЛ…

– Башта менюны тотып торучы төп ризык эзләдем. Ул тиз пешә торган, шул ук вакытта милли дә булырга тиеш иде. Замана кухнясына игътибар итсәгез, гамбургер, суши, шаурма кебек ризыклар камыр һәм эчлектән гыйбарәт. Шул вакытта кыстыбыйга тукталырга булдым. Аны бит нәрсә белән генә пешермиләр: бәрәңге дә, кабак та, тары боткасы да салалар. Мин исә үз эчлекләремне уйлап таптым. Мәсәлән, «Су анасы» дигән кыстыбый эчлеге балыктан ясала, «Дуслар» дигәне – тавык итеннән. Балалар өчен «Куян кучтәнәче» дигән җыелма бар. Кыстыбый – татарныкы, ләкин Чувашия, Киров өлкәсе, Удмуртиядә дә аңа охшаш ризыклар бар. Безнең кыстыбый Мексикадагы тако дигән ризыкка да бик охшаган, – ди Азат.

Кафены үстерү, популяр итү ягын Азат караса, бина эчендәге өй җылысы, атмосфера өчен тормыш иптәше Елена җавап бирә. Бу – аларның уртак җимеше. Яшьләр инде күптәннән якыннарны, туганнарны, гаиләгә әгъзаларын берләштерүче кафе турында хыялланганнар.

Хатыны дигәннән, Азат белән танышу Еленаның да тормышын тулысынча үзгәртә.

– Азат белән мөнәсәбәтләребез җитди төсмер алгач, хатыны – чиркәүгә, ире мәчеткә йөри торган гаилә булмый икәнен аңладым. Гаилә учагын саклаучы хатын-кыз буларак, ирем эзеннән киттем. Баштарак, Азаттан качып, ислам нигезләрен өйрәнә башладым, мәчеткә йөрдем. Азат, минем өчен генә динен алыштыра, дип әйтмәсен өчен яшердем моны. Ислам динендә өйрәтелгән гаилә кыйммәтләре ошады миңа. Гаиләдә һәр кешенең үз урыны бар, ир белән хатын бер-берсен хөрмәт итеп яши. Мине шаккатырган икенче әйбер – татарлардагы кунакчыллыгы. Иремнең әти-әниләре белән танышырга баргач күрдем моны. Кунак килү – сезнең өчен олы бер бәйрәм, барлык эшегезне ташлап, кунакны хөрмәтлисез. Мин боларның барысын да күреп, кызымның да шундый булып үсүен теләдем. Янәшәмдә принц булуын теләсәм, үземә дә принцесса булырга кирәк икәнен аңладым, – ди Елена.

ФАЙДАЛЫ ФАСТ-ФУД

Казанда кафе-ресторан күп, ләкин татарча, миллиләре сирәк. Булсалар да, гади халык кесәсенә яраклы түгел. «Кыстыбый» исә милли дә, файдалы да, очсыз да.

– Без үзебезне татар милли фаст-фуды дип йөртәбез. Халык арасында, фаст-фуд – зарарлы ризык, дигән стереотип яши. Безнең очракта фаст-фуд ул – тиз пешерү, тиз хезмәт күрсәтү дигән сүз генә. Без үзебез дә сәламәт яшәү рәвеше яклы. Камырны чүпрәсез ясыйбыз. Фаст-фудның төп проблемасы – составында. Без исә өйдә нинди ризыклар кулланабыз, шулардан ашарга пешерергә тырышабыз, – ди хуҗабикә.

Барлык азык-төлек Балтач районындагы Хәләл индустрия паркыннан кителә. Ризыклар хәләл стандартларына туры килә.

– Безнең кафе – тамак туйдыра торган гына җир түгел, ул аралашу урыны да. Атна саен мөселман кызлары өчен «Җомга-woman» чарасы бара, эшмәкәрләр җыела. Ял саен балалар һәм аларның ата-аналары өчен төрле остаханәләр эшли. Биредә балалар үзләре кыстыбый пешереп карый. Шулай ук бездә татар уеннары уйнап, татарча китаплар укып була. Үзебезчә, тамырларга кайту инде бу, – ди Азат.

– Берничә ел элек АКШта булдык, анда ял саен гаиләләр кафеларга җыелып аралашалар, ял итәләр. Бездә хәзер бер-береңә кунакка йөрү дигән гадәт бетә башлады. Хәзер яшьләр кунак чакыра башласа, стресс кичерә. «Ярты көн бәлеш әзерләү, табак-савыт юу, әбиләр көен көйләү, аннан ике-өч көн өй җыештыру…» – дип зарлана башлыйлар. Кунак җыю ул бәйрәм булырга тиеш. Без нәкъ менә шундый мәшәкатьләр булдырмас өчен, бу кафены ачтык та инде. Ашарга пешерүгә киткән вакытыңны карасаң, кафедагы ризык очсызгарак та чыга әле, – ди Елена.

ҺӘР ФИКЕР КЫЙММӘТЛЕ

Азат белән Еленаның эшмәкәрлеккә карата фикере дә кызыклы. Аларның кафе ачу тарихын социаль челтәрдә теләгән һәр кеше күзәтеп барды. Исем, кафе интерьеры, менюны да алар социаль челтәрләр аша булачак кунаклары фикеренә колак салып төзеде. Бизнес өлкәсенә әле яңа килгән кешеләргә аларның эше ресторан-бизнесында уку әсбабы дип тә карарга була моны.

– Халык кафе төзүдә үзе катнашты, бу – аларның да тырышлыгы. Теләгән һәр кеше безгә Инстаграм, «ВКонтакте» челтәрләрендә үз фикерен яза ала. Дөрес, безнең эзләрдән атлап, без барган юлдан баручылар да шактый хәзер. Ләкин конкуренциядән курыкмыйбыз. Ул безгә үсү өчен темп биреп тора. Безне кабатлыйлар икән, димәк, без – дөрес юлда. Көн саен яңа идея уйлап табабыз. Ә күчереп алу креатив фикерләүне киметә. Онлайн-режим кунакларның ышанычын арттыра. Аларның сораулары буенча без хәтта Инстаграмдагы туры эфир аша аш бүлмәсен, суыткычларны да күрсәтәбез, – ди Азат.

Киләчәктә яшьләр татар фаст-фуды белән бар дөньяны тутырмакчы. Башка төбәкләрдә Азат белән Елена кебек актив яшьләр франшиза аша «Кыстыбый» кафесын ача ала.

ЯШЕЛЧӘЛЕ КЫСТЫБЫЙ

Эчлек өчен баклажан, кызыл борыч, суган, сельдерейны ярым түгәрәк итеп турарга кирәк. Тоз, борыч, бераз тәмләткеч салып, яшелчәләрне зәйтүн маенда кыздырабыз. Яшелчә, ашаганда, бераз кытырдап торырга тиеш. Кыстыбыйны ясаганнан соң, кырыена чикләвек белән кәнҗет соусы салабыз.

ПОЧТАДАН

Ник мин ябыкмыйм?

«Шундый парк белән күрше яшәп, кит моннан, сиңамы ничек ябыгырга дип уйлап торырга, – диләр миңа хезмәттәшләрем, – атнасына бер-ике тапкыр урап чыксаң да, бөтен авырлыгыңны ташларсың». Шулай дигән булалар. Алар беләмени анда нинди тозак барлыгын! «Ярый, – мин әйтәм, – килегез, алып чыгам паркка, бергәләп ябыгырбыз».

Җыена торгач, тәки җыенып беттек. Чираттагы ялыбызда, иртәнге сәгать тугызда, кем әйтмешли, как штык, парк каршында очраштык бүлектәге алты хатын-кыз. Иң беренче, капкадан кереп бераз баргач, милли ризыклар сатыла торган «Түбәтәй» киоскы янында тукталдык. Бүлек җитәкчебезнең күзе анда сатыла торган өчпочмакларга төште. Җитәкчедән калышып булмый инде, әллә ни уйлавы бар – барыбыз да өчпочмаклар белән сыйландык. Борыннарны кытыклаган, авыздан сулар китереп, телеңне йотарлык тәмле исләр бассейн яныннан җәһәт кенә үтеп китәргә мәҗбүр итте. Без, яшь тайлар кебек, тәмле ис килгән якка ыргылдык. Югыйсә, коену костюмнарын да алган идек. Кафеда сыйлангач, ашаганны сеңдерик дип, аллея кырыена куелган эскәмияләргә утырып, роликлы тимераякта шуучыларны, велосипед, скейтбордларда йөрүчеләрне күзәттек. «Шахмат клубы» мәйданчыгында да булдык. Карап торучыларга кушылып, уйнаучыларга бәя биреп, хәтсез генә вакыт басып тордык.

Бераздан барыбызның да чәй эчәсе килә башлады. Чәй эчәсе килгән кешегә, Ходайга шөкер, паркта бөтен шартлар да тудырылган! Чираттагы кафега кереп, пирожныйлар белән рәхәтләнеп чәй эчтек. Вакытны бушка уздырмадык – тәрәзәдән җир стадионы – чирәмлектә ир-егетләрнең туп типкәннәрен карап утырдык. Шунда бер хезмәттәшебез: «Ярты көн үтеп тә киткән бит, кайтыйк, ашарга да әзерлисе бар», – диде. Тамак тук, өс бөтен дигәндәй, каршы килүче булмады.

Йә, әйтегез инде, нинди гаебем бар минем, парк белән күрше яшәп тә, һаман да ябыга алмаганга?!

Люция АБЛЕЕВА,
Казан.

Элек Колхоз базарына еш йөри идек. Азык-төлек алабыз да, автобуска утырып, рәхәтләнеп сөйләшеп, шәһәр күзәтеп кайтабыз. Берсендә шулай бер хатын белән танышып киттек. Үзенең гыйбрәтле хәлен сөйләде ул безгә.

Гомерең бетмәсә

Бу хатын ире белән икәү генә яшәгәннәр. Машиналары искерә башлагач, аны сатканнар. Тотылган «Жигули»дан килгән акчаны өйдә саклаганнар. Аскы каттагы күршеләре дә бу хакта белгән. Беркөнне алар «кунакка» кергәннәр. Ишекне ачуга, берсе бу хатынның иренә балта белән бәргән, хатынга да эләккән. Икесе дә идәнгә аңсыз ауганнар. Караклар исә ул арада акча эзләргә керешкән. Әле ярый икенче күршеләре тавыш ишетеп, юньлегә түгелдер дип, полиция хезмәткәрләрен чакырткан. Кыскасы, каракларны тоткарлаганнар. Кызганыч, балта белән башына сукканнан соң, ире гүр иясе булган. Хатынны да хастаханәдән моргка озатканнар. Мәетләр арасында берәүнең ыңгырашканын моргта җыештыручы ишеткән. Ни хикмәт, хатын үлеп җитмәгән булган. Аның башына тиз арада операция ясаганнар. Менә инде өч ел яши. «Кешенең гомере бетмәсә, үлми икән. Ирем генә янымда юк. Ә теге караклар төрмәдә утыра», – дип сөйләде ул. Кеше малына кызыгудан бер файда да юк шул.

Миңлегөл ӘДҺӘМОВА,
Казан.

КАЗАН



Тура базары шәһәрдән бераз читтәрәк, шуңа күрә ул озак кына вакыт халык өчен үз булып бетә алмады кебек. Әлбәттә инде, Яшел Үзән, Лаеш, Апас, Кайбыч районы халкы өчен ул бакча артында гына кебек. Шулай ук Арча, Балтач, Кукмара районнарыннан килүчеләр дә Казанга кермичә генә туры юлдан «Тура» базарына китсәләр, шәһәр ыгы-зыгысына эләкмичә генә исән-имин барып җитә алалар. Шәһәр эчендә йөреп өйрәнмәгән кеше өчен монысы да бик мөһим.

«Тура» базарының икенче үзенчәлеге: ул, беренче чиратта, күпләп сатып алучылар өчен кебек. Ләкин бу авыллардан, районнардан елына бер-ике тапкыр базарга килүчеләрне куркытмаска тиеш. Без сезнең белән хәзер нәкъ менә шушы үзенчәлекнең өстенлекләрен карап чыгарбыз.

ТУРА

БӘЯЛӘР

Кызыл эчле һәм сай «үзбәк» галошлары – **250 сум**
Урын-җир комплекты – **460 сумнан** (сыйфатына карап бәяләр арта)
Хатын кызлар өчен туникалар – **360 сумнан**
Сөлгеләр (120х90) – **200 сумнан**

Базарга килгәч тә беренче күргән әйберне алырга ашыкмагыз һәм монда бернинди җүнле әйбер юк, «базар хәерчесе» дип нәтиҗә дә чыгармагыз. Бәяләрне сорашып, карап, һич югы өч-дүрт рәт үтегез. Күпләп сатып алу базары булгач, сезгә, әлбәттә, «Берәү генәме, әллә күпләпме?» дигән сорау бирми калмаслар. Күпләп дигән сүз сезне куркытмасын. Өч, биш әйбер алсаң да, бер данәсе өчен булган бәяне өчәр, бишәр йөз сумга төшереп куярга мөмкиннәр. Башка базарлардагы кебек монда 50 сум, 100 сум ташлама ясап тормыйлар. Озакламый Соңгы кыңгырау бәйрәме җитә, шуны истә тотып, ак алъяпкыч белән форма күлмәк бәясен сорыйм. «Бөтен сыйныф белән сездән алсак, ташлама буламы?» – дип кызыксынам. Бер күлмәк алсаң – 1200 сум ди, инде бишне алсагыз – 700 сум. Сыйныф белән киңәшләшеп алганда, начар түгел бит. Әле эзләсәң, бәлки очсызгарак та табарга буладыр. «Миндә иң очсызы» дигән сүзгә дә бик ышанып җитәргә кирәкми. Сатучылары да, бәяләре дә бик төрле. Бер атлавы – мең алтын дип менә шушындый очракта әйтәләрдер инде. Ярты сәгать артыграк йөрсәгез дә шактый гына акчагыз янга калыр. Үзегезгә кирәкле товарларны нирәк кеше сатканын карагыз. Товарны үзе үк Төркиядән, Кытайдан, Мәскәүдән, Үзбәкстаннан, Кыргызстаннан алып кайтучы кеше икән, аның товары күпкә очсыз. Шушында ук базарның бер башыннан алып икенче башында өстәп сатып ятучылар да җитәрлек. Күземә беренче чалынган ирләр спортивкасын билгеләп куйдым да шуның бер үк сыйфатлысын 2000, 1500 һәм 1000 сумга күрдем.

Төркиядән товар алып кайтып сәүдә итүче Тамер белән сөйләшеп тордык.

– Миндә сатыла торган бу төр товарны сез биредә моннан да очсыз бәягә таба алмассыз. Мин үзем Төркиядән алып кайтам. Кайбер төр товарларны бөтен кеше миннән алып, бәя өстәп сата, – ди Тамер.

Икенче сәүдә итүче Солтан – үзбәк егете. Ул бирегә «Адмирал» базары янгач килгән.

– Бөтен товарларыбыз янып бетте. Җитмәсә тагын шунда яшәп ятканнар дип әллә нәрсәләр сөйләп, кимсетеп бетерделәр. Менә карагыз документларымны: мин – шәхси эшмәкәр, салым түләп торам, бернинди хокук бозмыйбыз. Товарны күбрәк Мәскәүдән ташыйбыз. Казан эчендә дә сәүдә ноктабыз бар. Бүген дөньядагы икътисад – кытайлар кулында, дияргә була. Менә гади генә марля. Аны Россиядә метрын тугыз сумга җитештерсәләр, аларда ул дүрт сум, сыйфаты да аерылмый. Алар моңа ничек ирешәләр – аптыраш. Әле бер Кытай сәүдәгәре белән аралаша башладым. Менә бу одеялны без Мәскәүдән 270 сумга алып кайтабыз. Тотып карады да мин сиңа аны 170 сумга китерәм, ди. Беләсезме, «Мега» сәүдә үзәгендә костюм сата торган эшмәкәрне белә идем, аның костюмнары 12000 сум тора. Үз күзләрем белән күрдем, ул да костюмнарын Кытайдан килгән сәүдәгәрдән 4000 сумга алды. Ышанасызмы, юкмы?! Миңа аларның шунысы ошый: халыкка менә хәзер нәрсә кирәк булачагын алар алдан тоеп, товар төрен үзгәртәләр дә куялар. Бүген сәүдәгәрләр өчен авыррак чор. Бәргәләнүдән файда юк. Сабыр гына үткәреп җибәрергә, булганны саклап калырга тырышырга кирәк, – диде ул.

Әлеге әңгәмәне тәфсилләп язуым юкка гына түгел, газета укучыларыбыз арасында алыпсатарлар булса, бәлки файдасы тияр. Тура базарында кызыл, зәңгәр биналар бар. Яшеле сатучылар белән тулы, кызылы яртылаш кына.

– Товарлар кызыл бинада очсызрак. Кирәкле әйберләрегезне иң элек моннан карагыз. Без бу бинага янгыннан соң күчендек һәм ул тулы да түгел, шуңа күрә безгә аренда бәясе дә түбәнрәк, сатып алучы өчен дә очсызрак. Ай саен түли торган аренда бәясе, сату ноктасының урынына карап, 18000 дә, 40000 дә булырга мөмкин, – диде яулыклар сатучы сәүдәгәр ханым.

Тура базарында сак хезмәте бик көчле икәнлеген дә әйтеп үтү кирәк. Сакчылар бик күп һәм алар барысын карап, күзәтеп кенә торалар. Уңайлыкларны барласак, акча алырга банкоматлар бар. Балаларга коляска, велосипедны арендага алып торып була. Базар иркен, җылы, балалар әниләре, әбиләре артыннан рәхәтләнеп йөри алалар. Кафеларның саны бихисап, нинди кухня кирәк – рәхим ит. Шушында ук чәч кистерергә дә, тырнак ясатырга да, самолетка, поездга билет алырга да була. Маршрут автобуслары да йөреп тора, машина кую өчен парковка бик зур һәм уңайлы. Азык-төлек кибете, даруханә – боларның барысы да бар.

Зөлфия ХӘЛИУЛЛИНА.

КОЛХОЗ БАЗАРЫ

Элек күз өстендәге каш булып торган Колхоз базарының «үзәк базар» дигән даны юк хәзер. Һәрхәлдә, миңа шулай тоелды. «Муравейник» кибете артында урнашкан кием-салым рәтләренең «Торговая слобода» янәшәсенә күчерелгәненә инде берничә ел. Бу вакыт эчендә сәүдә рәтләренең саны күпкә кимегән. Кием-салымны сайлап алу мөмкинлеге әллә ни юк.

Атна уртасы булгангамы шунда, бөтен базарга ун сатып алучы иде. Бәяләр белән кызыксынган арада, күршедәге ике сатучының сөйләшкән сүзләренә дә колак салам.

– «Порт»ка китәсеңме инде? – дип сорый берсе икенчесеннән.

– Китәм, анда кеше күбрәк йөри, – дип җавап кайтара тегесе.

– Анда бәяләр ничегрәк соң? – дип кушылам мин дә аларның сүзенә.

– Кыйммәтрәк, әмма товарлар әйбәт сатыла, – ди ул миңа.

Соңгы елларда Казанда кием-салым сатыла торган эре базарлар чынлап та шактый ачылды.

– Алар бит шәһәр читендә урнашкан. Авыл кешеләре хәзер машинада йөри, аларга анда барып кайту күпкә уңайлы. Монда исә тимер юл янәшә булганлыктан гына сату бара. Электричка белән килүчеләр кереп чыккалый. Шәһәрдә яшәүчеләр өчен безнең базар җайлырак, әлбәттә, бөтен төр транспорт йөреп тора. Тик алар хәзер сәүдә үзәкләренә йөри. Монда оекбаш, тастымал, кепка ише вак-төяккә генә киләләр. Аннары базарга килүчеләргә машиналарын куярга да урын юк, парковка түләүле, – ди Надя исемле сатучы.

Сатучыларның сүзләренә караганда, сатып алу җәй башында – балалар каникулга чыккач һәм август ахырында – уку елы башланганда җанланып ала.

– Балалар тиз үсә, җәйгә авылга яки лагерьга озатканда бер кат киендерәләр дә, аннары мәктәп формасы алырга төшәләр, – ди Гөлүсә.

Базар янындагы «Муравейник» кибетендә дә сатып алучылар аз. Анда өс киемнәренең бәяләре шактый кыйммәт, аның каравы күпкә сыйфатлырак. Чыгарылыш кичәсенә күлмәкләр 2000 сумнан 5000 сумга кадәр тора. Егетләргә күлмәкләр – 500 сумнан, костюмнар 2000 сумнан башлап. Биредә сатучылар да халыкның монда сирәк йөрүен әйтә.

«Торговая слобода» сәүдә рәтләрендә бәяләр базарныкы кебек. Сатып алучылар аз булгангамы шунда, анда күп кенә нокталар буш тора.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА.

БӘЯЛӘР

Носки (ун пар) – **150 сум**, аерым алсаң, берсе – **25 сум**
Балалар колготкие – **115 сум**
Спорт костюмы – **1500-1600 сум**
Кроссовкалар – **500-2000 сум**
Кепка – **250-350 сум**
Панамалар балаларныкы – **250-400 сум**, олыларныкы – **100-600 сум**
Җәйге ирләр күлмәге – **600 сум**
Сөлгеләр – **60-300 сум**
Хатын–кызлар күлмәге – **1000-1500 сум**
Урын-җирләре – **500-2000 сум**
Тастымаллар – **12-30 сум**
Кульяулыклар – **10-15 сум**
Капрон оек (10 данә) – **100 сум**
Галош – **250 сум**

БАЗАРЛАРЫ



ВЬЕТНАМ БАЗАРЫ

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

БӘЯЛӘР

Хатын-кызлар өчен комплект (туника һәм капри) – **350-800 сум**
Хатын-кызлар халаты – **350-600 сум**
Резин галош – **180-280 сум**
Кул сөлгесе – **35-100 сум**
Урын-җир (1,5) – **550 сумнан**, ике кешелек – **1000-2000 сум**
Ир-ат ноские – **25 сумнан**

Башкаланың Совет районында урнашкан Вьетнам базары – казанлыларга гына түгел, Арча, Биектау, Әтнә һәм Балтач районнары халкы өчен дә күпләп һәм берәмләп сатып алу урыны. 2014 елдагы янгыннан соң базар ике ел эшләми торган иде. 2016 елда ул кабат ачылды. Хәзер бина чиста, рәт аралары да киң, идәндәге иске линолеумны асфальт алыштырган, вентиляция эшләп тора. Бина янында гына ашханә һәм хәләл кафе эшли. Шулай ук машина кую урыны һәм инвалидлар өчен махсус билгеләнгән территория да бар. Базар янында ук төзелеш материаллары сатыла торган павильоннар да күп. Элегрәк биредә сату итүче халыкның күпчелеге вьетнамнар булса, хәзер Кавказ һәм Урта Азия кешеләре, руслар эшли. Транспорт мәсьәләсендә дә проблемалар юк. Базарга Казанның теләсә кайсы районыннан килеп җитеп була. Сатучыларның эш сәгатьләре иртәнге сигездә башлана һәм дүрттә тәгәлләнә.

Базарга атна уртасында чыгарга туры килде. Әйтергә кирәк, бу көнне биредә кеше аз йөри. Ә менә шимбә һәм якшәмбедә гөр килеп тора. Шуңа күрә, сатучыларның үзләренең сүзләре буенча, кием-салым бәяләрен алар ял көннәрендә киметеп бирергә риза түгелләр икән. Шулай да атна уртасында да күпләп сатып алырга теләүчеләр бар. Мәсәлән, үзбәк сатучысы Гөлшидә ханым әйтүенчә, ул андыйларга кием-салым бәясен шактый гына төшереп бирә.

– Мин үзем хуҗа кеше булгач, 100 сумга кадәр дә киметеп бирергә риза. 50 сумга да төшәм. Мәсәлән, 350 сумлык халатны, бишне алган очракта, 300 сумга бирәм. 400 сумлык хатын-кыз комплектларын да 300гә саткан вакытлар бар. 250 сумлык шорты белән футболканы 200гә бирәм, – ди ул.

Аның янында носкилар сатып торучы икенче бер сатучы да бер пары 25 сум торган ир-ат носкиен, күпләп алганда, 20 сумга бирәм, диде. Сөйләшү барышында аеруча Арчаның алыпсатар апалары үз итүе ачыкланды базарны. Алар биредән күпләп ир-атлар күлмәкләре, футболкалар, носки ише кием-салымны күпләп сатып ала икән.

Үзенчәлекле, яхшы сыйфатлы өске кием эзләүчеләр бик сирәк буладыр биредә. Чөнки монда күбесенчә носки, сөлге, йорт өчен кирәк-ярак, өйдә киеп йөри торган эчке кием сатыла.

Вьетнам базарыннан ерак түгел генә урнашкан Бик Зур һәм Алтын-Т сәүдә комплексына да кереп чыктык. Аралары әллә ни ерак булмаса да, вак-төяк кием-салымга (носки, эчке кием, сөлге), урын-җиргә бәяләр аермасы үзен сиздерә. Вьетнам базарында бәяләр арзанрак. Иркенләп эзләгәндә, яхшы гына сыйфатлы, матур, үзенчәлекле өске кием дә табарга була. Шуңа күрә эш, Сабан туе, чыгарылыш кичәләре, мәҗлесләр өчен күлмәктер, кофтадыр, итәктер, чалбардыр кирәк булганда, нәкъ менә шушында барырга киңәш итәр идем. Сатучылар әйтүенчә, монда күбесенчә казанлылар йөри.

Зөһрә САДЫЙКОВА.

КЫЗ БАЛАНЫ БӘЙРӘМГӘ КИЕНДЕРҮ

Бантик – **30 сумнан**
Кара күзлек – **100 сумнан**
Күлмәк – **350 сумнан**
Носки – **15 сумнан**
Туфли – **750 сумнан**

ПОРТ

БӘЯЛӘР

Галош – **250 сум**
Сөлге (120х90) – **250 сумнан алып**
Урын-җир комплекты (ике кешелек) – **1000-2700 сум**
Хатын-кызлар өчен комплект (туника һәм капри) – **400-500 сум**

Республика клиник хастаханәсе янында урнашкан «Порт» базары Лаеш ягыннан килүчеләр өчен җайлы. Әле бер еллап кына эшләсә дә, бу базар халык арасында популярлашырга өлгерде. Хәер, аны базар дип әйтеп тә булмый, зур сәүдә үзәге бу, барысы да заманча эшләнгән, бушлай машина кую урыннары бар, ял итү өчен эскәмияләр куелган.

«Порт»ка Казан үзәгеннән баруы гына җайсызрак. Машинасы булган кеше аптырамый анысы. Ә менә үз хуты белән килүчеләргә шактый ерак. Дөрес, «Порт»ка кадәр һәр 15 минут саен иртәнге сәгать җидедән бушлай автобуслар йөри. Тик алар Сахаров һәм Җиңү проспекты тукталышыннан гына китә. Базарга Чишмәле, Кол Гали, Фучик тукталышлары аша барабыз. Бушлай автобусны һәркем үз максатларында файдалана. Кемдер Җиңү проспектында төшеп кала, кемгәдер Республика клиник хастаханәсенә барырга кирәк. «Порт»ка кадәр салонда бары ике кеше генә утырып килдек. «Ял көннәрендә кеше күбрәк йөри», – ди автобус йөртүче.

Базарның аскы катында «Атак» кибете урнашкан. Ашамлыклар сата торган гипермаркет икән бу. «Ашан»ны хәтерләтә.Хәтта кайбер товарлар да – шундагы. Бәяләр арзан, сайлау мөмкинлеге зур. Базар кырыенда балаларга уйнар өчен мәйданчык та ясап куйганнар. Тәмәке тартучыларга аерым урын каралган.

Урамда велосипедлар, чәчәкләр саталар. Бер төп петуния үсентесе 25 сум тора. Портта күпләп алу урыннары да бар. Әйтик, ирләр өчен юка носкины берәмтекләп алсаң, берсен 40 сумнан саталар, ә күпләп алганда, ул 25 сумнан туры килә. Бер капта – 12 носки.

Рәт аралары киң, иркен. Эшкә урнашырга теләгән булып, бер сатучыдан биредә эшләү шартларын сорашам.

– Монда күбесе «Адмирал» базарында саткан кешеләр инде. «Муравейник», «Вьетнам» базарыннан да килүчеләр бар. Җылы, рәхәт. Эшләгән өчен көнгә 400 сум түлиләр. Сатудан 5 процент өстәлә. Эшкә бушлай автобуста киләбез. Сәгать алтыга кадәр сатабыз, – ди ялык япкан сатучы хатын.

Ул да түгел, хуҗасы стенадагы язуны, кеше күрсен өчен, өскәрәк эләргә куша. «Кием-салымны алыштырырга һәм кире кайтарырга ярамый» дип язылган элмә такта икән. Апаның хатын-кыз күлмәкләрен сатканын күреп гаҗәпләнеп карыйм.

– Яшь хуҗа. Аңламый. Закон буенча дөрес түгел инде. Әмма нишләтәсең, хуҗага каршы әйтеп булый. Сату начар бара бит, шуңа да төрле хәйләгә барырга туры килә, – ди әңгәмәдәшем.

Бер яшь кенә егет Әмәт бистәсеннән бирегә килеп эшли.

– Мәктәпне тәмамлауга, бирегә эшкә урнаштым, акча кирәк булды. Укыйсым килмәде.Монда татарлар күп килә. Әле ярый мәктәптә татар телен өйрәнгәнмен дип сөенәм, татарча дәшкәч, сатып алучы башкача карый, – ди егет.

Икенче катта аяк киемнәре саталар. Таҗик егетләре белән бәяне һәрчак килешеп була. 1000 сумлык кроссовканы, «беренче сатып алучы хөрмәтенә» дип, 500 сумга да бирергә әзерләр.

Саба районыннан килгән бер хатын белән танышып киттем. Гаиләсе белән Сабан туена дип киенергә килгәннәр. «Көтү чыкса, базар буенда йөрергә вакыт калмый», – ди Сания апа.

– Менә кызыма 1000 сумга – итәк, 1300 сумга блузка алдым. Үземә 1500 сумга күлмәк таптым. Джинс чалбарлар 800 сумга да бар икән. Сөт тапшырган айлык акчабыз җитә болай булса, – ди.

Улы социаль ипотека программасы буенча «Порт»тан ерак түгел фатир алган, аңа кунакка килгән саен базарга керми китмиләр икән. «Бәдрәф тә бушлай бит монда», – ди Сания апа. Тамак ялгар урын да бар.

Ашау дигәннән, чынлап та, «Порт»та кафелар җитәрлек. Берәр ризык алсаң, чәй йә каһвәне бушлай бирәләр. Сәгать 16.00дән соң камыр ризыкларына 30 процент ташлама каралган. Ризык – хәләл. Өчпочмакны – 30, бәрәңге боламыгын – 20, токмачны 15 сумга алырга була. «Порт»та даруханә, өй җиһазлары, савыт-саба сату бүлекләре дә бар. Балыкчылар өчен аерым алачык эшли. Әллә атна уртасы булганга, базарда кеше аз иде. Сатучылар моны күпләрнең базар турында белеп бетермәве белән аңлата. Сатып алучы булмаса да, сатучысы җитәрлек. «Порт»ның төп корпусы каршында күптән түгел тагын берсен ачканнар.

Эльвира МОЗАФФАР.

«ШӘҺРИ КАЗАН»нан – алма бакчасы

Бу язылу кампаниясендә укучыларыбызны нинди бүләк белән сөендерик икән, дип озак уйландык. Үзе файдалы да, истәлекле дә, матур да булсын иде ул бүләк. Уйлый торгач таптык тагын: без сезгә, Югары Ослан районының Ямбулат авылындагы «Заря» питомнигы белән берлектә, алмагач үсентеләре бүләк итәбез!

Бүләк алуның әллә ни кыенлыгы юк. Газетадагы анкетаны тутырып, 2017 елның II яртыеллыгына язылу турындагы квитанцияне редакциягә җибәрергә һәм жирәбә нәтиҗәләрен генә көтәргә кирәк. Үзегезгә ничек җайлы, шулай эшләгез, без аларны почта аша да, электрон адресыбызга да, «ватсап» аша да, социаль челтәрләрдәге төркемнәребездә дә кабул итәбез. Бүләк ике атна саен уйнатыла. Жирәбә уйнатуны видеога төшереп, **www.shahrikazan.com** сайтында урнаштырачакбыз.

Әйдәгез, алма бакчасында «Шәһри Казан» укыйк әле!

ИНДЕКСЛАР
П2430 – пәнҗешәмбе саны, ярты елга язылу бәясе – **415 сум 86 тиен.**

П2395 – атнага өч тапкыр: сишәмбе, пәнҗешәмбе, җомга көннәрендә чыга, ярты елга язылу бәясе – **854 сум 28 тиен.**

Языл

«Шәһри Казан» газетасына почта бүлекчәләрендә яки интернет аша языл

Анкетаны тутыр

Җибәр

Анкета, квитанцияләр, «Алмагач» дигән тамга белән, түбәндәге адресларга кабул ителә:
Почта аша: 420066, Казан, Чистай урамы, 5нче йорт, «Шәһри Казан» редакциясе
Электрон почта: shahri-kazan@tatmedia.com
Ватсап: 8 917-851-69-62
Социаль челтәрләрдәге төркемнәр: vk.com/shahrikazanda facebook.com/shahrikazan ok.ru/shrikazan

Шәһри КАЗАН
БЕЗ БЕЛГӘН ҺӘМ БЕЛМӘГӘН ШӘЙМИЕВ
Шәһри КАЗАН
САК ЙӨРЕГЕЗ ЗУР ЮЛЛАРДА
Шәһри КАЗАН
ҺӘРКЕМ ӨЧЕН УЗ КЕШЕ

Газетага ничек язылырга?

1. ТАТАРСТАННЫҢ ТЕЛӘСӘ КАЙСЫ ПОЧТА БҮЛЕГЕНДӘ

2. Казан шәһәрендә өегезгә дә килеп яздырабыз. Моның өчен **562-50-12** яки **8-917-851 69 62** номерларына шалтыратып, заявка калдырырга кирәк

3. ИНТЕРНЕТ АША – ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЛӘРЕ ПОРТАЛЫНДА

Моның өчен кул астында интернетка тоташкан берәр җайланма булуы гына кирәк
1. uslugi.tatarstan.ru сайтына кер;
2. «Подписка: газеты и журналы» дигән төймәгә бас;
3. Шәхси кабинетыңа кер;
4. «Шәһри Казан» (электрон каталогта – «Шахри Казан») газетасын сайла;
5. Адресыңны яз;
6. Дәүләт хезмәтләре порталы аша квитанцияне түлә.

Реклама

Тулырак мәгълүмат shahrikazan.com сайтында

АНКЕТА

1. Исем-фамилия, адрес, телефон______

2. Яшегез______

3. Шөгылегез______

4. «Шәһри Казан» газетасын кайчаннан бирле алдырасыз?______

5. Газета белән беренче тапкыр ничек һәм кайда таныштыгыз?______

6. Газетага ничек язылсасыз:

почта бүлекчәсендә _____

хат ташучы өйгә килә _____

интернет аша _____

7. Газетаны кайсы битеннән укый башлыйсыз?______

8. Сезне нинди эчтәлектәге язмалар җәлеп итә?______

9. Газетада тагын нинди темаларның күтәрелүен телисез?______

10. Газетаның миңа иң ошаган:______

ошамаган яклары:______

11. Тагын нинди газета-журналлар алдырасыз?______

Бәхет хатын-кыздан башлана

~ Ахирәт ~

Көчле булу да ярамый, кирәгеннән артык көчсез булып яшәү дә мөмкин түгел. Тик шулай да нәфис зат дип аталучы, һәрчак әлеге исеме җисеменә туры килеп үк бетмәгән, кайчак тупасланып, ир-атны өркеткән йөкне дә үз өстенә алырга әзер булган хатын-кыз бәхетле булу өчен нинди сыйфатларга ия булырга тиеш соң? Бу хакта психолог Ләлә БАҺРАМШИНА белән сөйләштек.

5 МИНУТЛЫК МАКИЯЖ

Тагын йоклап калгансызмы? 20 минуттан юынып, киенеп, ясанып, чәй эчеп эшкә йөгерергә кирәк! Тик бер дә кайгырмагыз. Тиз генә бизәнү буенча киңәш нәкъ менә сезнең өчен.

1нче минут. Биткә, күз кабакларына дымландыргыч крем сөртегез. Чәчне тарап, киенгәнче, бизәнү өчен бит әзер була.

2нче минут. Битегездәге җитешсезлекләрне корректор ярдәмендә яшерегез.

3нче минут. Йөзегезгә алсулык йөгертегез. Моның өчен елмаегыз һәм бит уртасындагы «алма»дан чигәгә таба кершәнне пумала белән түгел, бармаклар белән сөртегез.

4нче минут. Күз өстенә бераз гына ачык төстәге майлы сөрмә тартыгыз, керфекләрегезне буягыз.

5нче минут. Иренгә ачык төстәге яки үтә күренмәле ялтыравык иннек яисә бәлзәм сөртегез.

Гөлнара ЗИННӘТУЛЛИНА

– Ләлә Шаһиморатовна, гаилә бәхете дигәндә, ул күбрәк хатын-кыздан тора, диләр. Тик шулай да икесе ике «камыр»дан булган ир-ат белән хатын-кыз психолог күзлегеннән нәрсә өчен яратылган?

– Безнең чынбарлык эчке халәтебез белән бәйле. Әгәр тормышта бар нәрсә дә начар төсле тоела икән, димәк, синең эчке дөньяң тәртиптә түгел дигән сүз. Кыскасы, тирә-юньдә барган вакыйгалар синең күңел халәтеңнең көзгедәге чагылышы булып тора. Безнең ир-атлардан аермабыз шунда: алар алга карап максат куеп, шуңа бару юлларын эзли, ә хатын-кыз тактика төзи. Гүзәл зат ир-атның алдына куйган максатына ирешү юлындагы илһамландыручысы булып тора. Хатын-кыз, үзенең җылы сүзе, якты карашы белән, каршылыкларга очраган ир кешегә көч бирә.

Табигать кешене юкка гына парлы итеп яратмаган. Ә ялгыз тормыш алып баручы хатын-кызлар күп нәрсә югалтырга мөмкин. Чөнки максат куеп, тормыш өстерәү хатын-кыз өчен түгел. Үз максатына ирешү өчен, нәфис затка барыбер көчле зат ярдәме кирәк. Димәк, алар бер-берсен тулыландыру өчен яратылган.

– Барлык ир-атлар да үз артыннан ияртергә сәләтле түгел бит...

– Әлбәттә, андый очраклар юк дип әйтеп булмый, алар киресенчә, еш очрый. Бигрәк тә ир бала әнисе тәрбиясендә генә үскәндә, мондый күренешне күзәтергә мөмкин. Бу безгә сугыш елларыннан калган «мирас», чөнки күп гаиләдә малайлар әтисез тәрбияләнеп, көчле хатын-кызга – әнисенә буйсынып үсәргә мәҗбүр булган. Хатын-кыз күңелендә, ир баланы тәрбияләгәндә, ир-атка карата нәфрәт булмавы, көчле затка хөрмәт белән карый белүе мөһим. Чөнки әтисез малайны кушканны үтәүче, хатын-кызга буйсынучы итеп үстергәндә, аның нәтиҗәсе нинди булачагын кузаллау кыен түгел. Шуңа күрә ир баланы тәрбияләгәндә ир туганнар белән аралаштырсаң, төрле спорт секцияләренә, «Әтиләр клубы»на йөртсәң яхшы.

– Хәзерге заман кызлары кияүгә чыгам дип атлыгып тормый, гаилә корырга җыенганда да яшәр урыны, машинасы һәм яхшы эш урыны булуын шарт итеп куя, тик андыйлар санаулы бит.

– Әлбәттә, ир кешенең гаилә корганда күпмедер дәрәҗәдә матди яктан маясы, эш урыны һәм алга куелган максаты булса, бик яхшы. Тик әлеге матди байлыкны ир кеше үзе туплаганмы яисә ул аңа кемнән дә булса мирас булып күчкәнме – шунысы мөһим. Чөнки булган малны да тота һәм арттыра белү сәләте һәркемгә хас түгел. Тагын шунысын әйтергә кирәк: яшь чакта гаилә корып, максатларга бергәләп ирешкән парлар бәхетлерәк тә була. Мәсәлән, авылда яшәүчеләрдә кияүгә чыгу һәм өйләнүнең зарурлыгы язылмаган канун шикелле. Чөнки андагы тормышны хатын-кызга үзенә генә тарту мөмкин түгел. Алар балачактан гаилә корырга һәм парлы булырга кирәклекне сеңдереп үсәләр. Ә хәзерге заманда шәһәрдә яшәүчеләр башкачарак карый, чөнки шәһәрдә тормышны ир-атсыз да тартып була дигән уй хөкем сөрә. Әмма парлы тормыш алып барганда гына кечкенә генә тоелган уңышлар да чиксез бәхет хисе тудырырга сәләтле.

– Идеаль гүзәл зат нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?

– Социальләшү рәвешенә карап, хатын-кызларны дүрт төргә бүлеп йөртәләр.

1. «Хуҗабикә» хатын-кыз. Ул хуҗалык эшләре белән мәшгуль, юа, җыештыра, ашарга пешерә, балаларны, ирне хәстәрли, тик үзе турында онытып җибәрә. Татарларда мондый төр аеруча нык таралган. Бу безнең дин, гореф-гадәтләр белән дә бәйле.

2. «Сугышчы» хатын-кыз. Алар хаклык өчен көрәшүчеләр, гаиләсен яклау һәм саклау өчен көчен кызганмый. Куйган максатына, теләгенә ирешү өчен барысын да эшләргә сәләтле.

3. «Приз» хатын-кыз. Мондый хатын-кызның ире дә, үзе дә яхшы формада, чиста-пөхтә киенгән, балалары да «картинка» төсле. Әлеге гүзәл зат – презентация остасы, ул гаиләсен «Менә без шундый» дигән төсле күрсәтә белә, аларга читтән карап тору үзе бер рәхәт.

4. Илһам чыганагы булган хатын-кыз. Ул әллә ни эшләмәсә дә, гап-гади гамәлләре, ихласлыгы белән аерыла. Мондый гүзәл зат ир кешенең тормышына кыска вакытка килеп киткән очракта гына да, аны әллә нинди максатларга очындырырга, илһамландырырга сәләтле. Андыйларга багышлап, шагыйрьләр – шигырь, композиторлар көй яза.

Әлеге дүрт төрнең һәрберсенең уңай һәм тискәре яклары бар. Хатын-кыз өчен иң яхшысы – әлеге дүрт төрнең «микс»ы булу, ягъни тормышта туган вакыйгалар белән бәйле әлеге төрләрнең берсеннән икенчесенә җайлы гына күчә белү. Шулай эшли алганда, хатын-кыз беркайчан да югалып калмаячак һәм ул күп нәрсәгә сәләтле була. Ә мондый сыйфатлар гөлләмәсенең кайсысыдыр әниеңнән, туганыңнан күчсә, кайсыберсен дусларыңнан күреп үзеңә сеңдерергә яисә махсус тренингларга йөреп өйрәнергә мөмкин.

– Гомерлек тормыш иптәшен сайлаганда, аның турында алдан барысын да белеп бетерү мөмкин түгел. Акыл белән хисләр бер фикергә килеп, җаваплы адым ясаганда ничек хаталанмаска соң?

– Гаилә корыр алдыннан, әлбәттә, кайбер юк кына тоелган нәрсәләргә игътибар итәргә һәм үзеңне алдамый гына түбәндәге сорауларга җавап бирергә кирәк:

1. Әлеге ир-атка кияүгә чыккач, аның сыйфатларын һәм гадәтләрен үзеңнең туачак балаңда күрергә телисеңме? Әйе икән, димәк, ул – сезнең кеше.

2. Нинди дә булса бәхетсезлек очрагы туа калса, сайлаган кешең төрле хәлләр аркасында гарип калса, сәламәтлегенә зыян килсә, сукранмый гына тормыш йөген тартырга әзерме? «Әзер», – дип җавап бирәсез икән, ике дә уйламый, тәкъдимне кабул итә аласыз.

3. Булачак тормыш иптәшеңнең исе ошыймы? Ошаса, димәк, сезнең генофон төрле һәм балалар сәламәт туачак. Әгәр ир-ат белән хатын-кыза бер-берсенең тән исе ошамый икән, алга таба низаглардан качып булмый һәм алар гел бер-берсенең ачуын китереп торачак дигән сүз.

4. Динегез уртакмы? Уртак икән, димәк, гомер дәвамында күп кенә ризасызлык тудырырлык хәлләрдән сез азат дигән сүз.

Менә шушы сорауларга җавап биргәннән соң, нинди дә булса карар кабул итәргә мөмкин.

– Мәхәббәтнең гомере ике-өч ел гына, диләр, гаилә тормышының әлеге елларын алганнан соң, калганы бер-береңә түзеп яшәүгә генә кайтып калмыймы?

– Әлбәттә, мәхәббәтнең гомере кыска. Тик гаилә тормышында туган һәрбер вакыйга, яңалык, үзгәреш әлеге тоныклана барган хисләрне яңадан кабызырга сәләтле. Шуңа күрә ир белән хатын гомер дәвамында һәрчак үзгәреп үсештә булганда, гаилә таркалу куркынычы янамый.

ҺӘРКӨННЕ ИСТӘН ЧЫГАРМАСКА КИРӘКЛЕ 3 КИҢӘШ

Йокыдан уянуга сикереп торып, хуҗалык эшләренә кереп чуммаска, күзләрең ачылмас борын, эшкә йөгермәскә тырыш. Түбәндәге гап-гади киңәшләрне истә тотканда, йокыдан да тиз айнуның һәм кәефең дә күтәренке булыр.

1. Уянуга, урында яткан килеш бит, колак һәм кул чукларындагы акупунктур нокталарга массаж ясa.

2. Урында яткан килеш гәүдәңнең өске өлешен уңга борганда, аскы өлешен сулга борып, берничә минут күнегү ясa.

3. Бер аягыңның үкчәсе белән икенче аягыңның алгы өлешендәге биологик актив нокталар урнашкан тезгә кадәрге каты урынны уып ал.

БӘЯН-ХАТИРӘ

МӘҺДИЕВ ҺӘМ...

(Әсәрдән өзек)

Вакыйф НУРИЕВ

...ИПИ

Мөхәммәт МӘҺДИЕВ ЯЗА: *«Бар шундый малайлар – атна буе юкбарны ашап яшиләр дә шимбә көнне авылларына бер кирпеч ипи алып кайталар. Сугыш вакытында авылга атна саен бер кирпеч ипи кайтарып кара әле син! Дөньяда шуннан да зур байлык булырмы?» («Без – кырык беренче ел балалары»)*

ӘНИ СӨЙЛИ: «1943 елның җәй ахыры. Без Мөхәммәт Мәһдиев, Зөлхия Миңнекәева һәм мин (Арча районы Сеҗе авылына кияүгә чыгып, шунда кырык биш ел балалар укыткан әнием Нәкыя Абдуллина. – **В.Н.**) Яңа Чүриле районы Сикертән җидееллык мәктәбен «5»легә генә тәмамладык. Сүз куештык: Арча педагогия училищесына китәргә! Ул – урман артындагы Үрнәк бистәсендә. Документларыбызны тапшырдык. Хыялыбыз – укытучы булу! Әнинең мине җибәрәсе килми. Ничек җибәрәсе килсен, әти, абый – сугышта, мин – әни белән калган дүрт баланың кул арасына керә башлаган бердәнбере. Колхозда «помбригадир» булып эшлим. Укырга теләк шул кадәр зур ки, китәргә әзерләнәм, лапаста кача-поса чемодан ясыйм. Тактадан. Өйдә вак кадак таба алмадым. Йөзлене җибәрәм. Кадак тышкы якка чыкмасын дип, эчке якка авыштырыбрак кагам. Эш беткәч, чемоданны ачып карасам, бөтен кадак эчкә чыгып тырпаеп тора. Үзләрен бөгеп тә булмый.

Кичкә таба Гөберчәктән Мөхәммәт килде. Бер җәйдә буйга үсеп киткән, каралган. Үгез җигеп көлтә ташыган, җир сөргән. Шуларны сөйләде.

Иртәгесен әни басуга киткәч, эчен кадак камап алган чемоданымны алдым да Зөлхияләргә чаптым. Аннары ике кыз Гөберчәккә юл алдык. Анда безгә Мөхәммәт кушылды. Шулай итеп, өчәү юлга чыктык. Зур юлга! Белем юлына! Алда күпме михнәт, газап күрәсебезне без әле белмибез.

Өч классташ. Тактадан ясалган өч чемодан. Тузанлы юл…

Тирә-якта ни кычыткан, ни алабута калмаган. Барысын да ашап бетергәннәр.

И ул елларда… Үзәккә үтте ачлык. Әнинең: «һәй, балалар, балалар… Сезгә нәрсә ашатыйм инде мин», – дип, безне кочаклап елаганы хәтердә. Мөхәммәтләр дә ач. Әнисе каяндыр аз гына он юнәтеп, кычыткан ашына умач салган көн өйдә зур бәйрәмгә әверелә.

Май аенда шимбә көнне укудан кайтышлый Мөхәммәт, Зөлхия һәм мин Күчтем авылының бәрәңге басуына китәбез. Җилләнгән басуда кар астыннан чыккан, яңгыр, кар сулары юган бәрәңгеләр була. Шуннан әниләр күмәч пешереп бирә иде. Без аны дүшәмбе көнне үзебез белән алып китәбез һәм алты көнгә тигезләп бүләбез. Безгә аз гына эләккән шул черек бәрәңге күмәче дә ярап торды ул чакта.

Берсендә шулай, Чөмә-Елгадан Рафаэль Кадыйров (аның апасы Курса разъездында пекарняда эшли иде) дәрес вакытында Мөхәммәткә аз гына ипи сындырып бирде. Мөхәммәт аны шунда ук капты һәм, укытучыга сиздермәскә тырышып, чәйни дә башлады. Бәнәнә апа дәресе иде. Ул сизми каламы соң инде?! Безгә биргән сорауның җавабын Мөхәммәттән сорады. Мөхәммәт авызындагы ипиен чәйнәмичә генә йотарга мәҗбүр булды.

– Йоттыңмы инде? – дип сорады укытучы.

– Йоттым, апа, тик ипинең тәмен белмичә калдым, – диде Мөхәммәт, авыр сулап.

Училищеда безгә карточкага ипи бирәләр бит әле. Өйдәгеләр аны бөтенләй күрми ләбаса. Шуңа күрә безгә бирелгән ипине, ач булсак та, ашамаска тырышабыз. Аны каядыр ераккарак яшерәбез. Югыйсә, нәфесебезне тыя алмыйча, ашап бетерүебез бар.

Беркөнне бүлмәгә Мөхәммәт килеп керде. Миңа үзенең ипиен бирә.

– Нәкыя, чемоданыңа салып куй әле, – ди.

– Юк, юк, Мөхәммәт, салып куя алмыйм, – дим.

– Нигә салмыйсың?

– Чемоданымның биге начар. Ипиеңне урласалар… Сиңа ни дип җавап бирермен?!.

– И-и-и… Нәкыя, Нәкыя!.. Син кешенең башы ике дип беләсеңме әллә? Синең ул кадаклы чемоданыңа курыкмыйча кем кулын тыксын инде?!

1947 елның 20 августы. Яңа Чүриле районы үзәгенә конференциягә җыелдык. Мөхәммәт тә шунда. Мин, кечкенә гәүдәле, колакка да катырак булгач, алгарак утырдым. Зал тып-тын. Кемдер аркама кагылып алды. Ап-ак чәчле бер апа миңа мәктүп бирә. Борылуга, берничә рәт арттарак утыручы Мөхәммәтнең миңа туп-туры карап торуын сиздем. «Записка»ның аныкы икәнен шунда ук белдем. «Нәкыя, буфетта ипи саталар. Күпме алсаң да, бирәләр», дип язган ул. Эчемә шатлык сыймады. Тәнәфестә чиратка басып, ике ипи алдым. Димәк, өйгә энем һәм сеңелкәшләрем янына күчтәнәч белән кайтачакмын.

ХӘТЕРЕМ ДӘФТӘРЕННӘН: «Бер елны безне – бер төркем язучыларны Арчага чакырдылар. Уракның иң кызган вакыты иде. Безне басуларга алып чыгачаклар. Маршрут билгеле: Курса, Курса Почмак, Масра, Казанбаш, Гөберчәк, Сикертән… Юлыбыз туган авылым Сеҗе аша үтмәсә дә, сөендем. Күрше авыллар да минем туган як түгелмени?! Минем туган як түгелмени аларның басу-кырлары, урман-чытырманнары?! Атаклы Курсави, Ахун, Мәһдиевләрне биргән якка кайтабыз. Менә Мәһдиев язган «Пауал тегермәне» турысын, «торналар төшкән җир»не үтеп, «Масра басу»га күтәреләбез, аннары Гөберчәк урманына төбәп юл тотабыз. Якташ язучыбыз «дөньяның зыңлаганын» тыңлап торганда, «тын, бик тын» булган басуларда бүген «сабырлык, акыл чәчү» турында уйлап та булмый. Монда көрәш бара. «Ак барс» дип аталган хуҗалыгыбыз игенчеләре кырны штурмлый. Дөресен әйтим, мондый уңышны беркайда да күргәнем юк иде. Хикмәти Хода, шушы галәмәт минем туган ягымда бит әле. Җирне әйбәтләп эшкәртү, тиешенчә ашлау, сортлы орлык чәчүнең хикмәте икән. Ярый әле комбайннар зәһәр. Барысы да чит илнеке. Без белгән «СК»лар бу кырга керсә, икмәкне йота алмыйча, шунда ук тончыгачак ди. «Һоланд»лар артыннан сузылып калган пакусларны гына күр әле. Алар шундый калын, шундый биек ки, без утырган машина килеп бәрелер кебек.

Икмәк ташый торган «КамАЗ»лар берсе артыннан берсе китеп кенә тора. Башта алар кыр буйлап урманга менә. Аннары урман кырыеннан Гөберчәккә юл ала.

Алар нәкъ менә Мөхәммәт абый, Зөлхия апа, әниләрне ачка интектергән юлдан гәрәбәдәй сап-сары ашлык – ипи төяп чаба…»

...БҮРЕЛӘР

Мөхәммәт МӘҺДИЕВ ЯЗА: *«Безнең бабаларыбыз мәҗүсилек заманында бүре культына табынган булу ихтималын фольклорчылар еш әйтә. Шулайдыр, шулай булгандыр. Бүредән курку белән бергә халык күңеленең бик тирән төбендә бу хайванга курку катыш яшерен ихтирам, олылау хисе ятканын белмибезмени?*

– Кичә төнлә бүре килгән, – дип иртәгесен сөйләнгән хәбәр шом катыш серлелек, зурлык, әһәмиятлелек белән йорттан йортка йөри иде. Бүре килгән… Әйтерсең кабереннән торып борынгы баба, изге ата килеп киткән, ә без берни белмичә йоклап ятканбыз». («Торналар төшкән җирдә»)

ӘНИ СӨЙЛИ: «Ах ул бүреләр!.. Дүшәмбе укырга барганда, еш чыгалар иде. Таң сызылып кына килә, бүреләр инде ауда. Әтидән ишеткәнем бар иде, имеш, бүре сызгызы тавышыннан курка. Авыл малайларыннан бер сызгызы юнәткән идем. Берсендә шулай бүре чыккач, битемне кабарта-кабарта, шуңа өрә башладым. Сызгызымның сызгыруына бүренең койрыгы да селкенмәде. Мөхәммәт кенә миңа гаҗәпләнеп карап куйды:

– Нишлисең син, Нәкыя?

– Бүре куркытам.

– И-и-и… Нәкыя, Нәкыя!.. Болар бит – сугыш ягыннан качып килгән бүреләр. Болармы?.. Болар – «зениткалар», «артиллерия» һөҗүмнәрен күргән бүреләр. Снарядлар шартлавын ишеткән, пуля яңгырын кичкән бүреләр. Исләре китә синең сызгызыңа.

Бүре чыккач, Мөхәммәтнең безгә куйган таләбе – ерткычның күзенә карамаска, аңа арка белән басмаска. Иң шәбе – аңа ян белән тору. Кемдер, хәтерем ялгышмаса, Марсель Галиев бугай, язып та чыкты әле. Мәһдиев, сөйләшкәндә, әңгәмәдәшенә ян белән торуны кулай күрә, чөнки безнең татар сүзен тыныч кына әйтә алмый, корсакка, күкрәккә төртә башлый, дип. Бу сүзләр хактырмы, юктырмы? Хак икән, димәк, сабакташым саклану чараларын бүреләрдән өйрәнеп калган булып чыга түгелме?

Бүреләр, бүреләр. Ах ул бүреләр!..

Берсендә шулай карточкага ипи бирделәр. Бер атналык кирпеч ипи. Шуны тизрәк алып кайтып бирәсе, өйдәгеләрне сөендерәсе килә. Ачлар бит инде. Уйлаштык та авылга атна уртасында кайтып килергә булдык. Хәзергә әле юл да бар. Аннары кар явачак, бураннар башланачак. Мөхәммәт кайта алмады, ул – «дежурный». Аның безне җибәрәсе килмәде. Ни үгетләде, ни ялынды. Тыңламадык. Зөлхия белән кайтып киттек. Исән-имин кайтып җиттек.

Сеңелкәшләрне, энекәшләрне сөендердек. Төнге өчтә китәргә чыктык. Дәрескә өлгерәсе бар. Училищеда тәртип кырыс. Биш минутка гына соңга калсаң да – куалар! Гөберчәкне үттек, урманга җиттек. Уңда – урман, сулда – кыр. Сулыш алырга да куркып барабыз. Отыры таң беленә башлады. Төнлә кырпак кар яуган. Кыр ала-кола булып ята. Басуга түгелгән тирес өемнәре дә ала-тилә. Чү! Шул өемнәрнең берсе селкенә башлады. Икенчесе дә, өченчесе дә шуып барган кебек. Минем күзәмә генә шулай күренәме соң? Зөлхиядән сорыйм. Ул җан ачысы белән кычкырып җибәрде:

– Нәкыя! Бүреләр!!!

– Бүреләр?!.

Әнә, тезелешеп, кырны ярып, урманга таба менеп баралар. Нәкъ безнең каршыга чыгарга чамалый болар. Баш бетте болай булгач.

Мөхәммәт!.. Зөлхия белән икебез дә берьюлы әйттек бу исемне. Их, Мөхәммәт! Кичә сүзеңне нигә җиргә салдык икән?! Күңелдә – үкенү, үкенү, үкенү… Яныбызда син булсаң иде хәзер. Ерткычлар белән дә уртак тел таба беләидең бит син.

Күңелнең бик тирән бер почмагында, «бәлки, бүреләр юл аша чыгарлар да урманга кереп китәрләр», дигән өметле уй да бар иде әле. Аларның юл буенда түгәрәкләнеп утыруларын күргәч, ул өмет тә киселде. Ерткычлар урманга да кереп китмәде, безгә дә карамады. Гамьсез генә оеп утыра бирделәр. Без ни алга, ни артка бара алмыйбыз. Елыйбыз. Безне бүреләрдән куркып елыйлар, дип уйлыйсызмы? Куркабыз инде. Сүз дә юк. Юлдан каршыбызга бер хатын-кыз килүен күргәч, бүреләрдән курку хисе бераз басылгандай булды. Әмма ул хатынны күреп, сөенергә дә, сөенмәскә дә белмәдек. Алда безгә дәһшәтлерәк куркыныч яный бит әле – без дәрескә соңга калачакбыз. Безне училищедан куачаклар!

Озак утырды бүреләр. Тирләгәннәр, пешкәннәр. Сыртларыннан пар күтәрелә. Яктыргач кына берсе – араларында иң зурысы торып басты. Вожактыр инде ул. Биек чыршыларга карап, ым какты. Бүре көтүе ашыкмый, акрын гына, дәрәҗәсен белеп кенә шомлы урман куелыгына кереп югалды. Алар утырган урында, кар эреп, кучкыл түгәрәкләр хасил булган иде. Ә теге хатын Тылаңгырныкы булып чыкты. Гөберчәккә барышы икән.

Хәлбуки, без училищега килеп кергәндә, дәресләр башланган иде инде. Язмышыбыз бик тиз хәл ителде. Бусаганы атлап керүебез булды, директор үзе басып тора инде. Ул: «Хәзер үк күземнән югалыгыз! Ычкыныгыз моннан! Приказ чыгар!» – дип кычкырды да китеп барды.

Без тулай торакка кайтып елашып утырганда, Мөхәммәт килеп керде. Беренче тәнәфескә чыгуга, безнең янга йөгергән. Борчылуы йөзенә чыккан. Аңа ниләр булганын сөйләдек. Ул: «Беркая китмәгез! Бүлмәгездә генә утырыгыз», – диде дә икенче дәрескә йөгерде. Кичкә таба Мөхәммәт бүлмәбезгә балкып-сөенеп килеп керде. «Кызлар! Борчылмагыз. Училищеда каласыз. Приказ булмаячак!» – диде ул. Шатлыгыбыздан нишләргә белмәдек. Укудан соң Мөхәммәт Тылаңгырга барган. Теге хатынны эзләп тапкан. Аны директорга алып килгән. Безгә очраган юлчы иртәнге вакыйганы түкми-чәчми сөйләп биргән. Шул төнне бүреләрнең Тәрнәледәге фермага кереп бөтен сарыкны буып чыгулары турында да хәбәр таралган. Аны директор да ишеткән. Шушы, иртән без күргән бүреләр җиткән бит инде ул бичара сарыкларның башына. Тәрнәле ягыннан менделәр дә шул. Корсакларын кан белән тутырган тук бүреләр булган алар. Әйтәм аны, безгә борылып та карамадылар. Аларның безгә – яшь кызларга карата булган битарафлыгына ачуыбыз да килмәде микән әле».

ХӘТЕРЕМ ДӘФТӘРЕННӘН: «Казанда, университетта беренче курста укып йөргән чагым. Беренче сессия. Беренче имтихан. Мин авылда әзерләнәм. Өйдә үзем генә. Әти-әни эштә. Укып ятам. Башым революцияләр, съездлар, сугышлар белән тулы. Күз алдымда саннар биешә. Ул даталарны ничек хәтердә калдырып бетермәк кирәк. Укыдым-укыдым да урам әйләнеп кайтырга булдым. Төтен баганалары белән күкне терәтеп торган ак авыл. Ак дөнья. Һаваның сафлыгыннан баш әйләнә. Клуб тәрәзәсендә ут бар. Сугылып чыгыйк иттем. Керсәм… университетта безне татар теленең нечкәлекләренә өйрәтүче укытучыбыз Хәлил Сәлимов елмаеп басып тора:

– Син бу авылданмыни?

– Әйе, минем туган авылым. Сезне нинди җилләр ташлады?

– Без концерт белән кайттык. Таһир Якупов, Нәфисә Василова.

→ Ахыры бар.

КУНАКТА

«Танылу Азатны үзгәртте»

Чувашия Республикасындагы Шыгырдан авылы (Батыр районы) турында ишетмәгән кеше юктыр. Россиядәге иң эре авылларның берсе ул. Бу авыл – яшь һәм өметле җырчы, Рәшит Ваһапов исемендәге Халыкара татар җыры фестивале лауреаты Азат Абитовның туган җире дә. Биредә аның әти-әнисе, туганнары, дуслары яши. Әтисе Фәрид Батыр районының мәдәният йортында музыкант һәм тавыш режиссеры булып эшли, ә әнисе Альбина Шыгырдан урта мәктәбендә музыка дәресләрен укыта, музыка мәктәбендә баян дәресләрен бирә. Альбина ханым белән очрашып сөйләшкәч, Азат турында тагын да күбрәк белдек. Әңгәмәдәшемнең сүзләрендә, күзләрендә, елмаюында әниләрчә ихлас, күңелнең иң түреннән бөркелеп чыга торган чиксез ярату һәм матур горурлык хисләре дә тойдым мин.

Зөһрә САДЫЙКОВА,
Чувашия, Шыгырдан

– Альбина ханым, Азатның җыр-моңга сәләте кемнәрдән килә, моң чишмәсенең башы кайларга барып тоташа, дигән сорау урынсыз булыр иде. Җыр сәнгате, моң дигән төшенчәләр сезнең гаилә өчен бер дә ят түгел икән.

– Чыннан да, иремнең дә, үземнең дә музыкаль белемебез бар. Әтиебез җырлар яза, гармунда уйный, балалар белән дә ул шөгыльләнә иде. Олы улыбыз Раил дә бик матур җырлый иде. Азатка караганда да моңлырак бала булгандыр әле, бәлки, әмма бик җитди авариягә эләккәч, җырламый башлады. Хәзерге вакытта барысы да яхшы, хатыны һәм баласы бар.

– Азат дөньяга аваз салган көннәр хәтерегездә ничек уелып калган? Ул балачагында шук, шаян идеме, әллә киресенчәме?

– Азат – безнең икенче балабыз. Ул вакытларда УЗИ юк иде, нишләптер, күңелем белән аны кыз бала булыр дип көттем. Бәлки, шуңадыр да, тыйнаклык бар аңарда. Олы улыбыз белән аралары зур түгел. Ике абый-эне бергә уйнап үсте. Өченче балабыз Эльвина мәктәптә укый. Азат кечкенә чагында бик шаян, шук иде. Хәзер аңардан күп сүз тартып ала алмассың. Мәктәптә укыган елларда да йөзебезгә кызыллык китергәне булмады. Директорыбыз Гөлсирин Абәйдуллова да балаларның сәләтләрен күреп, аларны дөрес юлга куя белә. Бервакыт ул Азатка: «Азат улым, сәхнәгә кәгазь тотып чыкма», – дигән иде. Шушы киңәшне ул бервакытта да исеннән чыгармый. Ваһапов фестиваленә катнашканда Азат 100 җырның сүзен яттан белә иде.

– «Шәһри Казан»га биргән әңгәмәсендә Азат: «Венера Ганиева оештырган «Сандугач-Соловей» бәйгесендә беренче турны да үтә алмагач, төшенкелеккә бирелеп кайтып киттем. Әти-әнигә рәхмәт, үземдә яңадан ышаныч табарга алар ярдәм итте. «Бу әле җиңелергә сәбәп түгел», – дип, әти көн-төн репетицияләр ясатты», – дигән иде.

– Ул чагындагы уңышсызлыгының сәбәбе – таныш булмаган җыр башкаруындадыр дип уйлыйм. Азат әтисенең җырын җырлаган иде бит. Ул мәктәптә укыган елларда һәрвакыт беренче булды. Ә әлеге бәйгегә уза алмагач, бераз төшенкелеккә бирелеп алды да кабаттан Ваһапов фестиваленде катнашу теләге белән яна башлады. Моңа күп көч куйды. Әтисенең аппаратураларын алып кайтып, үзлегеннән шөгыльләнеп, конкурска җиде җыр яздырып җибәрде. Һәм эшенең нәтиҗәсе – чакыру хатын алды.

– Проектның авторы һәм җитәкчесе Рифат Фәттаховның Азатка зур өметләр баглавы сизелә. Казанда узган концертына да билетлар сатылып бетте, дигән иде. Яшь җырчы өчен бу – зур күрсәткеч. Тамашачының мәхәббәтен яулап баручы җырчы булудан тыш, улыгызның тагын нинди сыйфатлары белән горурланасыз?

– Азат – бик ышанычлы, җаваплы бала. Максатына үз тырышлыгы белән бара торган кеше. Безгә, туганнарга, дусларына бик мәрхәмәтле. Ниндидер бер матбугат чарасында Азат турында тәкәббер дип укыганым бар. Мондый фикер белән килешмим. Ул артык сүз сөйләшми, бәлки әлеге сыйфаты аркасында язма авторында шундый тәэсир калдыргандыр. Өмет дигәннән, дөресен әйтәм, Азатның Казанда узган концерты вакытында без бәхетнең җиденче катында идек. Аны хәтта аңлатып та булмый. Тамашачыларның көчле алкышлауларын күреп, моңа ышаныргамы-юкмы дип утырдык. Ирем Фәридкә: «Азатка түгел, оркестрга кул чабалардыр шулкадәр», – дип әйтүем хәтердә. Әмма бу алкышлар чыннан безнең улыбызга иде.

– Хәзер Азат авылга еш кайтамы һәм буш вакытларын гадәттә ничек уздыра?

– Хәзер бик еш кайта алмый. Аена яки ике атнага бер тапкыр була торгандыр. Кайткач, безгә булыша, дуслары, туганнары белән көрәшә. Гаиләбезнең матур традициясе бар – туган көннәребездә барлык туганнар, дуслар белән җыелу, көрәшү. Зу-ур табын корабыз. Моннан кала, тагын бер матур гадәтебез бар. Ерак юллардан кайткач, дини бәйрәмнәрдә, һичшиксез, иремнең төп йортына барабыз. Мәчеттән соң зиярәт кылгач, нәселебезнең бөтен ир-аты Азатның әби-бабасы туган шушы нигезгә җыела. Хәзер анда иремнең абыйсының гаиләсе яши. Алар һәр кешене матур итеп каршы ала. Мин үзем Себердә үскәнлектән, туганнарым шунда калды. Монда иремнең алты бертуганының гаиләләре белән һәрвакыт аралашып яшибез.

– Альбина ханым, балаларыгызны тәрбия кылганда нинди принципларга таянасыз?

– Әтиләре дә, үзем дә балаларда кешеләргә карата хөрмәт тәрбияләдек. Чөнки әгәр шуны тәрбияли алсак, ул үзебезгә үк кире әйләнеп кайтасын беләбез. Кешеләргә яхшы сүз кызганмагыз, дип, гел әйтә киләбез.

– Әни кеше буларак, балагызны сездән дә яхшырак белүче юк. Әйтегез әле, татар тамашачысы алдында танылу Азатны үзгәрттеме?

– Үзгәртте, әлбәттә. Азат үсеп китте, тагын да җаваплылык өстәлде. Рәшит Ваһапов фестиваленнән соң өйгә кайткач, ул: «Әти, әни, Рифат абый миңа продюсерлык итү буенча тәкъдим ясады. Нәрсә эшлим икән?» – дип киңәш сорады. Дөресен генә әйткәндә, ул мондый тәкъдимне көтмәгән иде һәм аңа әзер түгел иде. Киңәшләшкәч, уйлашкач, эшләргә карар кылды. Һәм менә ике ел узып та китте инде. Без бу мәсьәләдә бераз гына эшләр башкарган идек тә, әмма эстрада юлыннан ялгызыңа гына бару бик авыр. Ә Рифат абый аңа чыннан да зур ярдәм итә. Без аның үзенә дә, монда кайткач: «Сез Азатка Казанда әти ролендә», – дидек. Моны күңелебез белән сизмәгән булсак, әйтмәс идек. Әни кеше буларак, Рифат абыйга бик ышанам. Азатка да: «Алынгансың икән, ничек кенә авыр булса да, ахырга кадәр барырга кирәк. Ямьсезләнеп йөрерлек булмасын», – дибез.

– Улыгызга нинди теләктә торасыз?

– Бәхет, күңел тынычлыгы телим. Алла теләсә, калганнары барысы да була. Кеше бөтен яктан бәхетле булырга тиеш. Бүгенгә Азат шушы юлга басуы, Рифат абый кебек кешеләр белән эшләвенә бәхетле. Күптән түгел генә Балтач якларында гастрольләрдә йөреп кайттылар. Өлкән яшьтәге бер әбидән безгә атап язылган хат белән бүләкләр дә алып кайтты Азат. Бик матур сүзләр бар иде анда. Без хатны тормыш иптәшем белән елый-елый укыдык. Хәзергә менә шул вакытларда шуннан да зуррак бәхет юктыр кебек. Туганнарга да укыдык ул хатны. Аннан соң Гөлсирин, Рәнис (Габбазов) кебек дуслары булу да зур куаныч. Алар безгә кунакка кайткач, сөйләгән сүзләре, корган планнары белән бер тарафта иканлекләрен күрдем. Һәм улыбызга, әлбәттә, матур гаилә корырга да язсын иде дип телим.

15 МАЙ – ДҮШӘМБЕ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 «Җырлыйк әле!» (6+)
05:50 Татарстан хәбәрләре (12+)
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:00 Новости Татарстана (12+)
08:10 «Народный будильник» (12+)
09:00 «Последний янычар». Телесериал (12+)
10:00 «Ак чәчәкләр». Телесериал (12+)
10:50 «Канун. Парламент Җәмгыять» (12+)
11:30 «Секреты татарской кухни» (12+)
12:00 «Участок». Телесериал (12+)
13:00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа (12+)
14:00 «Закон. Парламент. Общество» (12+)
14:30 Новости Татарстана (12+)
14:45 «Хочу мультфильм!» (0+)
15:00 «Күчтәнәч» (0+)
15:15 «Без тарихта эзлебез» (6+)
15:40 «Җырлы-моңлы балачак»(0+)
16:00 «Энид Блайтон. Секретная книга». Телесериал (6+)
17:00 «Ак чәчәкләр». Телесериал (12+)
18:00 «Татарлар» (12+)
18:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
19:00 «Таяну ноктасы» (16+)
19:30 Новости Татарстана (12+)
20:00 «Вызов 112» (16+)
20:10 «Тукай урамында»(0+)
20:15 «Күчтәнәч» (0+)
20:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
21:00 «Чёрное озеро» (16+)
21:30 Новости Татарстана (12+)
22:00 «Вызов 112» (16+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:05 «Әдәби хәзинә» (12+)
08:30 «Яшәсен театр!» (0+)
09:00 «Яңалыклар» (12+)
09:20 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
10:05 «Кайнар хит» (12+)
11:00 «Татарлар» (12+)
11:30 «Белем дөньясы» (6+)
12:00 «Яңалыклар» (12+)
12:20 «Гашыйк йөрәк». Телесериал (12+)
13:10 «Караоке татарча» (0+)
13:25 «Без тарихта эзлебез» (0+)
14:00 «Үткәннәр сагындыра» (0+)
14:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
15:00 «Яңалыклар» (12+)
15:15 «Күчтәнәч» (0+)
15:30 «Тамчы-шоу» (0+)
16:00 «Үткәннәр сагындыра» (0+)
16:10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
18:00 «Яңалыклар» (12+)
18:20 «Гашыйк йөрәк». Телесериал (12+)
19:10 «Халкым минем» (12+)
19:40 «Туган җир» (12+)
20:05 «Татарлар» (12+)
20:30 «Таяну ноктасы» (16+)
21:00 «Яңалыклар» (12+)
21:20 «Күчтәнәч» (0+)
21:40 «Караоке татарча» (0+)
21:55 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
6.05, 7.05, 8.05 «Вести – Татарстан. Погода»
6.35, 7.35, 8.35 «Вести – Татарстан. Утро»
11.40 «Парламентские вести»
14.40 «Яңалыклар. Татарстан»
17.20, 20.45 «Вести – Татарстан»

ПЕРВЫЙ
05.00 Телеканал «Доброе утро».
09.00 Новости.
09.20 Контрольная закупка.
09.50 «Жить здорово!» (12+)
10.55 Модный приговор.
12.00 Новости с субтитрами.
12.15 «Наедине со всеми». (16+)
13.20 «Время покажет». (16+)
15.00 Новости с субтитрами.
15.15 «Время покажет». (16+)
16.00 «Мужское / Женское». (16+)
17.00 «Давай поженимся!» (16+)
18.00 Прямой информационный канал «Первая Студия». (16+)
20.00 «Пусть говорят» с Андреем Малаховым. (16+)
21.00 Время.
21.30 Т/с Премьера. «Власик. Тень Сталина». (16+)

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России».
09.00 Вести.
09.15 «Утро России».
09.55 «О самом главном». (12+)
11.00 Вести.
11.40 Вести. Местное время.
11.55 Т/с «Склифосовский». (12+)
14.00 Вести.
14.40 Вести. Местное время.
14.55 Т/с «Тайны следствия». (12+)
17.00 Вести.
17.20 Вести. Местное время.
17.40 «Прямой эфир». (16+)
18.50 «60 минут». (12+)
20.00 Вести.
20.45 Вести. Местное время.
21.00 Т/с «Капитанша». (12+)

16 МАЙ – СИШӘМБЕ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 «Музыкаль каймак» (12+)
05:50 Татарстан хәбәрләре (12+)
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:00 Новости Татарстана (12+)
08:10 «Народный будильник» (12+)
09:00 « Последний янычар». Телесериал (12+)
10:00 «Ак чәчәкләр». Телесериал (12+)
10:50 «Туган җир» (12+)
11:30 «Секреты татарской кухни»(12+)
12:00 «Участок». Телесериал (12+)
13:00 «Путь» (12+)
13:15 «Фолиант в столетнем переплете» (12+)
13:30 «Не от мира сего...» (12+)
13:45 Документальный фильм (12+)
14:15 «Дорога без опасности» (12+)
14:30 Новости Татарстана (12+)
14:45 «Хочу мультфильм!» (0+)
15:00 «Күчтәнәч» (0+)
15:15 «Әдәби хәзинә» (12+)
15:40 «Җырлы-моңлы балачак»(0+)
16:00 «Энид Блайтон. Секретная книга». Телесериал (12+)
17:00 «Ак чәчәкләр». Телесериал (12+)
18:00 «Татарлар» (12+)
18:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
19:00 «Таяну ноктасы» (16+)
19:30 Новости Татарстана (12+)
20:00 «Вызов 112» (16+)
20:10 «Тукай урамында» (0+)
20:15 «Күчтәнәч» (0+)
20:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
21:00 «Чёрное озеро» (16+)
21:30 Новости Татарстана (12+)
22:00 «Вызов 112» (16+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:05 «Без тарихта эзлебез» (0+)
08:30 «Яшәсен театр!» (0+)
09:00 «Яңалыклар» (12+)
09:20 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
10:10 «Җырлыйк әле!» (6+)
11:05 «Татарлар» (12+)
11:30 «Халкым минем» (12+)
12:00 «Яңалыклар» (12+)
12:20 «Гашыйк йөрәк». Телесериал (12+)
13:10 «Караоке татарча» (0+)
13:25 «Әдәби хәзинә» (12+)
14:00 «Үткәннәр сагындыра» (0+)
14:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
15:00 «Яңалыклар» (12+)
15:15 «Күчтәнәч» (0+)
15:30 «Поем и учим татарский язык» (0+)
15:45 «Җырлы-моңлы балачак» (0+)
16:00 «Үткәннәр сагындыра» (0+)
16:10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
18:00 «Яңалыклар» (12+)
18:20 «Гашыйк йөрәк». Телесериал (12+)
19:10 «Башваткыч» (6+)
20:05 «Татарлар» (12+)
20:30 «Таяну ноктасы» (16+)
21:00 «Яңалыклар» (12+)
21:20 «Күчтәнәч» (0+)
21:40 «Караоке татарча» (0+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
6.05, 7.05, 8.05 «Вести – Татарстан. Погода»
6.35, 7.35, 8.35 «Вести – Татарстан. Утро»
9.00 «Мир культуры»
9.25 «Вячеслав Власов. Страницы моей жизни». Телефильм
11.40 «Вести – Татарстан»
14.40 «Яңалыклар. Татарстан»
17.20, 20.45 «Вести – Татарстан»

ПЕРВЫЙ
05.00 Телеканал «Доброе утро».
09.00 Новости.
09.20 Контрольная закупка.
09.50 «Жить здорово!» (12+)
10.55 Модный приговор.
12.00 Новости с субтитрами.
12.15 «Наедине со всеми». (16+)
13.20 «Время покажет». (16+)
15.00 Новости с субтитрами.
15.15 «Время покажет». (16+)
16.15 «Мужское / Женское». (16+)
17.15 Чемпионат мира по хоккею-2017. Сборная России – сборная США. Прямой эфир из Германии. В перерыве – Вечерние новости с субтитрами.
19.25 «Пусть говорят» с Андреем Малаховым. (16+)
21.00 Время.
21.35 Т/с Премьера. «Власик. Тень Сталина». (16+)

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России».
09.00 Вести.
09.15 «Утро России».
09.55 «О самом главном». (12+)
11.00 Вести.
11.40 Вести. Местное время.
11.55 Т/с «Склифосовский». (12+)
14.00 Вести.
14.40 Вести. Местное время.
14.55 Т/с «Тайны следствия». (12+)
17.00 Вести.
17.20 Вести. Местное время.
17.40 «Прямой эфир». (16+)
18.50 «60 минут». (12+)
20.00 Вести.
20.45 Вести. Местное время.
21.00 Т/с «Капитанша». (12+)

17 МАЙ – ЧӘРШӘМБЕ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 «Җырлыйк әле!» (6+)
05:50 Татарстан хәбәрләре (12+)
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:00 Новости Татарстана (12+)
08:10 «Народный будильник» (12+)
09:00 «Последний янычар». Телесериал (12+)
10:00 «Ак чәчәкләр». Телесериал (12+)
10:50 «Ватандашлар» (12+)
11:30 «Секреты татарской кухни» (12+)
12:00 «Участок». Телесериал (12+)
13:00 «Каравай» (6+)
13:30 «Наша республика.Наше дело» (12+)
14:30 Новости Татарстана (12+)
14:45 «Хочу мультфильм!» (0+)
15:00 «Күчтәнәч» (0+)
15:15 «Яшьләр тукталышы» (12+)
15:40 «Җырлы-моңлы балачак» (0+)
16:00 «Энид Блайтон. Секретная книга». Телесериал (6+)
17:00 «Ак чәчәкләр». Телесериал (12+)
18:00 «Татарлар» (12+)
18:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
19:00 «Таяну ноктасы» (16+)
19:30 Новости Татарстана (12+)
20:00 «Вызов 112» (16+)
20:10 «Тукай урамында» (0+)
20:15 «Күчтәнәч» (0+)
20:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
21:00 «Чёрное озеро» (16+)
21:30 Новости Татарстана (12+)
22:00 «Вызов 112» (16+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:05 «Әдәби хәзинә» (12+)
08:30 «Яшәсен театр!» (0+)
09:00 «Яңалыклар» (12+)
09:20 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
10:15 «Башваткыч» (6+)
11:05 «Татарлар» (12+)
11:30 «Туган җир» (12+)
12:00 «Яңалыклар» (12+)
12:20 «Гашыйк йөрәк». Телесериал (12+)
13:10 «Караоке татарча» (0+)
13:25 «Без тарихта эзлебез» (0+)
14:00 «Үткәннәр сагындыра» (0+)
14:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
15:00 «Яңалыклар» (12+)
15:15 «Күчтәнәч» (0+)
15:30 «Поем и учим татарский язык» (0+)
15:45 «Җырлы-моңлы балачак» (0+)
16:00 «Үткәннәр сагындыра» (0+)
16:10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
18:00 «Яңалыклар» (12+)
18:20 «Гашыйк йөрәк». Телесериал (12+)
19:10 «Җырлыйк әле!» (6+)
20:05 «Татарлар» (12+)
20:30 «Таяну ноктасы» (16+)
21:00 «Яңалыклар» (12+)
21:20 «Күчтәнәч» (0+)
21:40 «Караоке татарча» (0+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
6.05, 7.05, 8.05 «Вести – Татарстан. Погода»
6.35, 7.35, 8.35 «Вести – Татарстан. Утро»
11.40 «Вести – Татарстан»
14.40 «Яңалыклар. Татарстан»
17.20, 20.45 «Вести – Татарстан»

ПЕРВЫЙ
05.00 Телеканал «Доброе утро».
09.00 Новости.
09.20 Контрольная закупка.
09.50 «Жить здорово!» (12+)
10.55 Модный приговор.
12.00 Новости с субтитрами.
12.15 «Наедине со всеми». (16+)
13.20 «Время покажет». (16+)
15.00 Новости с субтитрами.
15.15 «Время покажет». (16+)
16.00 «Мужское / Женское». (16+)
17.00 «Давай поженимся!» (16+)
18.00 Прямой информационный канал «Первая Студия». (16+)
20.00 «Пусть говорят» с Андреем Малаховым. (16+)
21.00 Время.
21.35 Т/с Премьера. «Власик. Тень Сталина». (16+)

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России».
09.00 Вести.
09.15 «Утро России».
09.55 «О самом главном». (12+)
11.00 Вести.
11.40 Вести. Местное время.
11.55 Т/с «Склифосовский». (12+)
14.00 Вести.
14.40 Вести. Местное время.
14.55 Т/с «Тайны следствия». (12+)
17.00 Вести.
17.20 Вести. Местное время.
17.40 «Прямой эфир». (16+)
18.50 «60 минут». (12+)
20.00 Вести.
20.45 Вести. Местное время.
21.00 Т/с «Капитанша». (12+)

18 МАЙ – ПӘНҖЕШӘМБЕ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 «Башваткыч»(6+)
05:50 Татарстан хәбәрләре (12+)
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:00 Новости Татарстана (12+)
08:10 «Народный будильник» (12+)
09:00 «Последний янычар». Телесериал (12+)
10:00 «Ак чәчәкләр». Телесериал (12+)
10:50 «Белем дөньясы» (6+)
11:30 «Секреты татарской кухни»(12+)
12:00 «Участок». Телесериал (12+)
13:00 «Каравай»(6+)
13:30 Документальный фильм (6+)
14:30 Новости Татарстана (12+)
14:45 «Хочу мультфильм!» (0+)
15:00 «Күчтәнәч» (0+)
15:15 «Әдәби хәзинә»(12+)
15:40 Мультфильмы (0+)
16:00 «Энид Блайтон. Секретная книга». Телесериал (6+)
17:00 «Ак чәчәкләр». Телесериал (12+)
18:00 «Татарлар» (12+)
18:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
19:00 «Таяну ноктасы» (16+)
19:30 Новости Татарстана (12+)
20:00 «Вызов 112» (16+)
20:10 «Тукай урамында» (0+)
20:15 «Күчтәнәч» (0+)
20:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
21:00 «Чёрное озеро» (16+)
21:30 Новости Татарстана (12+)
22:00 «Вызов 112» (16+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:05 «Без тарихта эзлебез» (0+)
08:30 «Яшәсен театр!» (0+)
09:00 «Яңалыклар» (12+)
09:20 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
10:10 «Күңелем назлары җырымда чагыла...» Татарстанның халык артисты Флүра Сөләйманова турында телеочерк (6+)
11:05 «Татарлар» (12+)
11:30 «Яшьләр тукталышы» (12+)
12:00 «Яңалыклар» (12+)
12:20 «Гашыйк йөрәк». Телесериал (12+)
13:10 «Караоке татарча» (0+)
13:25 «Әдәби хәзинә» (12+)
14:00 «Үткәннәр сагындыра» (0+)
14:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
15:00 «Яңалыклар» (12+)
15:15 «Күчтәнәч» (0+)
15:30 «Поем и учим татарский язык» (0+)
15:45 «Җырлы-моңлы балачак» (0+)
16:00 «Үткәннәр сагындыра» (0+)
16:10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
18:00 «Яңалыклар» (12+)
18:20 «Гашыйк йөрәк». Телесериал (12+)
19:10 «Ком сәгате» (12+)
20:05 «Татарлар» (12+)
20:30 «Таяну ноктасы» (16+)
21:00 «Яңалыклар» (12+)
21:20 «Күчтәнәч» (0+)
21:40 «Караоке татарча» (0+)
21:55 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
22:40 «Янар чәчәк». Мирсәет Яруллин турында телеочерк (12+)
23:35 «Яшәсен театр!» (0+)
00:00 «Яңалыклар» (12+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
6.05, 7.05, 8.05 «Вести – Татарстан. Погода»
6.35, 7.35, 8.35 «Вести – Татарстан. Утро»
9.00 «Музыкальная жизнь»
9.35 «Современник». Маргарита Коварская
11.40 «Вести – Татарстан»
14.40 «Яңалыклар. Татарстан»
17.20, 20.45 «Вести – Татарстан»

ПЕРВЫЙ
05.00 Телеканал «Доброе утро».
09.00 Новости.
09.20 Контрольная закупка.
09.50 «Жить здорово!» (12+)
10.55 Модный приговор.
12.00 Новости с субтитрами.
12.15 «Наедине со всеми». (16+)
13.20 «Время покажет». (16+)
15.00 Новости с субтитрами.
15.15 «Время покажет». (16+)
16.00 «Мужское / Женское». (16+)
17.00 «Давай поженимся!» (16+)
18.00 Прямой информационный канал «Первая Студия». (16+)
20.00 «Пусть говорят» с Андреем Малаховым. (16+)
21.00 Время.
21.35 Т/с Премьера. «Власик. Тень Сталина». (16+)
23.40 «Вечерний Ургант». (16+)
00.15 Ночные новости.
00.30 Х/ф «Чужой-4: Воскрешение». (16+)

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России».
09.00 Вести.
09.15 «Утро России».
09.55 «О самом главном». (12+)
11.00 Вести.
11.40 Вести. Местное время.
11.55 Т/с «Склифосовский». (12+)
14.00 Вести.
14.40 Вести. Местное время.
14.55 Т/с «Тайны следствия». (12+)
17.00 Вести.
17.20 Вести. Местное время.
17.40 «Прямой эфир». (16+)
18.50 «60 минут». (12+)
20.00 Вести.
20.45 Вести. Местное время.
21.00 Т/с «Капитанша». (12+)
23.15 «Поединок». Программа Владимира Соловьёва. (12+)
01.15 Т/с «Шерлок Холмс». (12+)

19 МАЙ – ҖОМГА

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 «Халкым минем...» (12+)
05:25 «Нәсыйхәт» (6+)
05:50 Татарстан хәбәрләре (12+)
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:00 Новости Татарстана (12+)
08:10 «Народный будильник » (12+)
09:00 «Последний янычар». Телесериал (12+)
10:00 «Ак чәчәкләр». Телесериал (6+)
10:50 «Нәсыйхәт» (6+)
11:30 «Секреты татарской кухни» (12+)
12:00 «Участок» . Телесериал (12+)
13:00 «Башваткыч» (6+)
14:00 «Актуальный ислам» (6+)
14:15 «Все суры Корана» (6+)
14:30 Новости Татарстана (12+)
14:45 «Хочу мультфильм!» (0+)
15:00 «Күчтәнәч» (0+)
15:15 «Тамчы-шоу» (0+)
15:40 «Җырлы-моңлы балачак» (0+)
15:55 «Зебра» (0+)
16:05 «Энид Блайтон. Секретная книга». Телесериал (6+)
17:00 «Ак чәчәкләр». Телесериал (6+)
18:00 «Туган җир» (12+)
18:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
19:00 «Белем дөньясы» (6+)
19:30 Новости Татарстана (12+)
20:00 «Вызов 112» (16+)
20:10 «Тукай урамында» (0+)
20:15 «Күчтәнәч» (0+)
20:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
21:00 «ДК» (12+)
21:15 «Дорога без опасности» (12+)
21:30 Новости Татарстана (12+)
22:00 «Вызов 112» (16+)
22:10 «Наша республика. Наше дело» (12+)
23:00 «Последний янычар». Телесериал (12+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:05 «Без тарихта эзлебез» (0+)
08:30 «Яшәсен театр!» (0+)
09:00 «Яңалыклар» (12+)
09:20 «Язгы гөлем». ИлСаф концерты (0+)
10:10 «Ай нурына тулган моң». Римма Ибраһимова турында телеочерк (6+)
11:05 «Татарлар» (12+)
11:30 «Яшьләр тукталышы» (12+)
12:00 «Яңалыклар» (12+)
12:20 «Гашыйк йөрәк». Телесериал (12+)
13:10 «Караоке татарча» (0+)
13:25 «Әдәби хәзинә» (12+)
14:00 «Үткәннәр сагындыра» (0+)
14:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
15:00 «Яңалыклар» (12+)
15:15 «Күчтәнәч» (0+)
15:30 «Поем и учим татарский язык» (0+)
15:45 «Җырлы-моңлы балачак» (0+)
16:00 «Үткәннәр сагындыра» (0+)
16:10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
18:00 «Яңалыклар» (12+)
18:20 «Гашыйк йөрәк». Телесериал (12+)
19:10 «Ком сәгате» (12+)
20:05 «Татарлар» (12+)
20:30 «Таяну ноктасы» (16+)
21:00 «Яңалыклар» (12+)
21:20 «Күчтәнәч» (0+)
21:40 «Караоке татарча» (0+)
21:55 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
6.05, 7.05, 8.05 «Вести – Татарстан. Погода»
6.35, 7.35, 8.35 «Вести – Татарстан. Утро»
9.00 «Рухи хәзинә»
9.40 «Время «Татнефти»
11.40 «Вести – Татарстан»
14.40 «Яңалыклар. Татарстан»
17.20 «Вести Приволжского федерального округа»
20.45 «Вести – Татарстан»

ПЕРВЫЙ
05.00 Телеканал «Доброе утро».
09.00 Новости.
09.20 Контрольная закупка.
09.50 «Жить здорово!» (12+)
10.55 Модный приговор.
12.00 Новости с субтитрами.
12.15 «Наедине со всеми». (16+)
13.20 «Время покажет». (16+)
15.00 Новости с субтитрами.
15.15 «Время покажет». (16+)
16.00 «Мужское / Женское». (16+)
17.00 Жди меня.
18.00 Вечерние новости с субтитрами.
18.45 «Человек и закон» с Алексеем Пимановым. (16+)
19.50 «Поле чудес». (16+)
21.00 Время.
21.30 Премьера. «Победитель».
23.00 «Вечерний Ургант». (16+)
23.50 Т/с «Фарго». Новый сезон. «Городские пижоны». (18+)

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России».
09.00 Вести.
09.15 «Утро России».
09.55 «О самом главном». (12+)
11.00 Вести.
11.40 Вести. Местное время.
11.55 Т/с «Склифосовский». (12+)
14.00 Вести.
14.40 Вести. Местное время.
14.55 Т/с «Тайны следствия». (12+)
17.00 Вести.
17.20 Вести. Местное время.
17.40 «Прямой эфир». (16+)
18.50 «60 минут». (12+)
20.00 Вести.
20.45 Вести. Местное время.
21.00 «Петросян-шоу». (16+)
23.15 Х/ф «Мой папа лётчик». (12+)

20 МАЙ – ШИМБӘ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 Концерт (6+)
07:00 «Sиңа Миннән Sәлам» (6+)
09:30 «Автомобиль» (12+)
10:00 «Кайнар хит»(12+)
11:00 «Халкым минем...» (12+)
11:30 «Секреты татарской кухни» (12+)
12:00 «Каравай» (6+)
12:30 «Видеоспорт» (12+)
13:00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» (12+)
13:30 «Созвездие-Йолдызлык – 2017» (0+)
14:30 «Ялкынлы яшьлегем эзләре». Шагыйрь Мансур Шиһаповның иҗат кичәсе (6+)
16:00 «Нәсыйхәт» (6+)
16:30 «Татарлар» (12+)
17:00 «Без тарихта эзлебез» (6+)
17:30 «Әдәби хәзинә» (12+)
18:00 «КВН РТ-2017» (12+)
19:00 Документальный фильм (12+)
19:30 Новости в субботу (12+)
20:00 «Адымнар»(12+)
20:30 «Җырлыйк әле!»(6+)
21:30 Новости в субботу (12+)
22:00 «Ищу невесту без приданого». Художественный фильм (12+)
23:45 «Малавита». Художественный фильм (16+)
01:40 «Китәм, димә...». Телевизион нәфис фильм (12+)
03:15 «Мәхәббәт чишмәләре». Зөһрә Шәрифуллина җырлый (0+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Оч, син, җырым...» Популяр җырлар авторы Рәмис Аймәт концерты (12+)
07:00 «Sиңа Миннән Sәлам» (6+)
09:30 «Шаян хәлләр» (16+)
10:00 «Кайнар хит» (12+)
11:00 «Башваткыч» (6+)
11:50 «Җырлыйк әле!» (6+)
12:45 «Язмышым җырларымда». Алсу Хәбибуллина концерты (12+)
14:30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» (12+)
15:00 «Sиңа Миннән Sәлам» (6+)
17:30 «Нәсыйхәт» (6+)
18:00 Г.Камал. «Беренче театр». Телеспектакль (6+)
18:55 «Кичке аш» (6+)
19:20 «Башваткыч» (6+)
20:10 «Җырлыйк әле!» (6+)
21:00 «Адымнар» (12+)
21:30 М.Фәйзи. «Галиябану». Телеспектакль (12+)
00:00 «Синең җырларыңны көйләп...» Әлфия Авзалованың туган көне уңаеннан (12+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
8.00, 11.20 «Вести – Татарстан»
8.20 «Доброе утро, Татарстан!»

ПЕРВЫЙ
06.00 Новости.
06.10 Х/ф «Государственный преступник».
08.00 Играй, гармонь любимая!
08.45 М/с «Смешарики. Новые приключения».
09.00 Умницы и умники. (12+)
09.45 Слово пастыря.
10.00 Новости с субтитрами.
10.15 Д/ф Премьера. «Дневник охранника вождя». (12+)
11.20 Смак. (12+)
12.00 Новости с субтитрами.
12.15 «Идеальный ремонт».
13.15 «На 10 лет моложе». (16+)
14.00 Х/ф «Свадьба в Малиновке».
15.55 Премьера. «Вокруг смеха».
18.00 Вечерние новости с субтитрами.
18.15 «Творческий вечер Константина Меладзе».
20.00 «Кто хочет стать миллионером?» с Дмитрием Дибровым.
21.00 Время.
21.20 «Сегодня вечером» с Андреем Малаховым. (16+)
23.00 Х/ф «Геракл». (16+)
00.50 Х/ф «Большие надежды». (16+)
02.50 Х/ф «Буч и Сандэнс: Ранние дни». (12+)

РОССИЯ 1
05.15 Х/ф «Особенности национальной маршрутки». (12+)
07.10 «Живые истории».
08.00 Вести. Местное время.
08.20 Россия. Местное время. (12+)
09.20 Сто к одному.
10.10 «Пятеро на одного».
11.00 Вести.
11.20 Вести. Местное время.
11.40 Аншлаг и Компания. (16+)
14.00 Вести.
14.20 Х/ф «Одиночка». (12+)
16.20 «Золото нации».
18.00 Субботний вечер.
20.00 Вести в субботу.
21.00 Х/ф «Храни тебя любовь моя». (12+)
00.55 Х/ф «Простить за всё». (12+)

21 МАЙ – ЯКШӘМБЕ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 Концерт (6+)
08:00 «Адымнар» (12+)
08:30 Мультфильмы (0+)
09:00 «ДК» (12+)
09:15 Документальный фильм (12+)
09:45 «Тамчы-шоу» (0+)
10:15 «Яшьләр тукталышы» (12+)
10:45 «Музыкаль каймак» (12+)
11:30 «Секреты татарской кухни»(12+)
12:00 «Каравай» (6+)
12:30 Документальный фильм (12+)
13:00 «Закон. Парламент. Общество» (12+)
13:30 «Адымнар» (12+)
14:00 «Созвездие-Йолдызлык – 2017» (0+)
15:00 «Ком сәгате» (12+)
16:00 «Җырлыйк әле!» (6+)
17:00 «Видеоспорт» (12+)
17:30 «Әдәби хәзинә» (12+)
18:00 «Башваткыч» (6+)
19:00 Телефильм (12+)
19:30 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа (12+)
20:30 «Болгар радиосы»концерты (6+)
21:30 «Кичке аш» (6+)
22:00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа (12+)
23:00 «Помпеи». Художественный фильм (12+)
00:50 Л. Лерон. «Бәхеткә биш минут кала». Буа татар дәүләт театры спектакле (12+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Бәхетем башкаласы». Концерт (6+)
07:50 «Улым». Гүзәл Уразова һәм Илдар Хәкимов концерты (6+)
09:25 «Яшьләр тукталышы» (12+)
09:55 «Тамчы-шоу» (0+)
10:20 «Поем и учим татарский язык» (0+)
10:30 «Җырлыйбыз да биибез» (0+)
11:00 «Белем дөньясы» (6+)
11:30 «Халкым минем» (12+)
12:00 ТВ фондыннан. «Җырлый Руслан Дәминов» (6+)
12:30 «Татарлар» (12+)
13:00 «Нәсыйхәт» (6+)
13:30 «Җитте шундый вакытларым». Зөһрә Шәрифуллинаның юбилей концерты (6+)
16:05 «Ватандашлар» (6+)
16:30 «Музыкаль каймак» (12+)
17:20 «Әдәби хәзинә» (6+)
17:50 «Без тарихта эзлебез» (0+)
18:20 «Болгар радиосы» концерты (6+)
19:10 «Ком сәгате» (12+)
20:05 «Мин – Буран кызы!» Хәмдүнә Тимергалиеваның юбилей концерты (12+)
22:15 «Шаян хәлләр» (16+)
23:20 «Халкым минем» (12+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
10.20 «Вести – Татарстан. События недели»

ПЕРВЫЙ
05.00 Х/ф «Ищите женщину».
06.00 Новости.
06.10 Х/ф «Ищите женщину».
08.05 М/с «Смешарики. Пин-код».
08.25 «Часовой». (12+)
08.55 «Здоровье». (16+)
10.00 Новости с субтитрами.
10.15 «Непутевые заметки» с Дмитрием Крыловым. (12+)
10.35 «Пока все дома».
11.25 Фазенда.
12.00 Новости с субтитрами.
12.15 «Идеальный ремонт».
13.15 Д/ф «Теория заговора». (16+)
14.20 Д/с Премьера. «Страна советов. Забытые вожди». (16+)
16.30 Премьера. «Шансон года». (16+)
18.20 «Аффтар жжот». (16+)
19.30 Премьера. «Лучше всех!»
21.00 Воскресное «Время».
22.30 «Клуб Веселых и Находчивых». Высшая лига. (16+)
00.45 Х/ф «Канонерка». (16+)

РОССИЯ 1
05.00 Х/ф «Особенности национальной маршрутки». (12+)
07.00 Мульт-утро.
07.30 «Сам себе режиссёр».
08.20 «Смехопанорама» Евгения Петросяна.
08.50 Утренняя почта.
09.30 Сто к одному.
10.20 Местное время. Вести-Москва. Неделя в городе.
11.00 Вести.
11.20 Смеяться разрешается.
13.10 «Семейный альбом». (12+)
14.00 Вести.
14.20 Х/ф «Чужое лицо». (12+)
16.15 Х/ф «Сжигая мосты». (12+)
20.00 Вести недели.
22.00 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». (12+)
00.30 Д/ф «Русская Антарктида. XXI век». (12+)
02.20 Х/ф «Испытательный срок».

Первый, Россия1 каналларының программасы «Сервис-ТВ» АҖдан алынды

«ТАТАРСТАН» радиосы

15 МАЙ – ДҮШӘМБЕ

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы
6.04 «Нефть чыккан якларда»
6.15 «Музыкаль мизгелләр»
6.35,10.00,18.10 Яңалыклар. Новости
6.45 «Юллар чатында»
6.50,7.50,10,55,13.55,18.55 Прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-10.00, 11.00-12.10, 13.00-13.10, 14.00-18.10,19.00 Трансляция радио России
10.10,13.10 Туфан Миңнуллин. «Яшьлегем – җуләрлегем».
12.10-13.00 «Татарстан дулкынында»
18.25 «Сердәшханә»
18.40 «Җыр – минем гомерлек юлдашым».

16 МАЙ – СИШӘМБЕ

6.00-8.00 «Новый день». Панорама событий
6.04 «Актуальное интервью»
6.15 «Музыкаль мизгелләр»
6.35,10.00,13.10,18.10 Яңалыклар. Новости
6.50,7.50,10.55,13.55,18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Диалог в прямом эфире
8.00-10.00,11.00-12.10,13.00-13.10,14.00-18.10,19.00 Трансляция радио России
10.10 «Пар канатлар»
12.10 «Татарстан дулкынында»
13.20 «Әй матур дөнья!»
18.25 Гармунчы Фәйзулла Туишев, җырчы Зөләйха Хисмәтуллина язмалары

17 МАЙ – ЧӘРШӘМБЕ

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы
6.04 «Нефть чыккан якларда»
6.15 «Музыкаль мизгелләр»
6.35,10.00,13.10,18.10 Яңалыклар. Новости
6.50, 7.50, 10.55, 13.55, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-10.00,11.00-12.10,13.00-13.10,14.00-18.10,19.00 Трансляция радио России
10.10 «Актуальное интервью»
10.35 «Старт»
12.10-13.00 «Татарстан дулкынында»
13.20 «Яшьлек аланы»
18.25 «Идел егетләре» эстрада-вокаль ансамбле концерты

18 МАЙ – ПӘНҖЕШӘМБЕ

6.00-8.00 «Новый день». Панорама событий
6.04 «Перекресток»
6.15 «Музыкаль мизгелләр»
6.35,10.00,13.10,18.10 Яңалыклар. Новости
6.50,7.50,13.55,18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Диалог в прямом эфире
8.00-10.00,11.00-12.10,13.00-13.10,14.00-18.10,19.00 Трансляция радио России
10.10 «Доброе братство лучше богатства» (на башкирском языке)
10.35 «Время молодых»
12.10-13.00 «Татарстан дулкынында»
13.20 «Офыклар»
18.25 «Тагын хуш ис бөрки сиреньнәр». Лирик концерт

19 МАЙ – ҖОМГА

6.00-8.00 «Иртәнге нур»
6.15 «Музыкаль мизгелләр»
6.35,10.00,13.10,18.10 Яңалыклар. Новости
6.50,7.50,13.55,18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00-7.10 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-10.00,11.00-12.10,13.00-13.10,14.00-18.10,19.00 Трансляция радио России
10.10 «Вдохновенья миг»
12.10-13.00 «Татарстан дулкынында»
13.20 «Әй матур дөнья!» ®
18.25 Кытайда яшәүче татарлар җырлый

20 МАЙ – ШИМБӘ

10.10 «Гөлбакча»
10.30 «7 көн». Атналык күзәту
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.00-12.10,13.00-13.10,14.00-15.10, 16.00 Трансляция радио России
12.10-13.00 «Татарстан дулкынында».
13.10 Татар халык көйләре
15.10 Миргазиян Юныс. «Табу һәм югалту». Радиотамаша. 1нче өлеш

21 МАЙ – ЯКШӘМБЕ

8.00-9.00 «Между Волгой и Уралом». Объединенный радиожурнал семи республик
9.00-10.10, 11.00-12.10,13.00-13.10, 14.00-15.10,16.00-16.10,17.00 Трансляция радио России
10.10 «Көмеш кыңгырау»
10.30 «7 дней». Обзор событий
10.55,13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
12.10-13.00 «Татарстан дулкынында»
13.10 Ял концерты
15.10, 16.10 Миргазиян Юныс. «Табу һәм югалту». Радиотамаша. 2-3нче өлешләр

ЯЛ ПОЧМАГЫ



Аермалар тап



СКАНВОРД

Материк
Якутия елгасы
Австрия мәркәзе
Абакан елгасы кушылдыгы
Берәр нәрсәнең бик нечкә аерымлыклары
Документ
Актриса Разумовская
Аркылы
Берәр әдәби әсәрне иҗат итүче

Оча торган тәлинкә
Сорау алмашлыгы
Вердиның «Травиата» операсы персонажы
Япония шәһәре
Тәңре
Җиздән эшләнгән тынлы уен коралы төре

Америка актрисасы Лонгория
Табибларның эш урыны
Бакый дөньяның кересе
Хатын-кыз күлмәгенең билдән өске өлеше
Татар халык җыры
Кар төсе
Ир бала
Татар ир-атлары исеме
Украина акча берәмлеге
Аксыл кызыл
Хуш исле суганчалы декоратив үсемлек
Мексикадагы штат
Элеп кую
Газета-журнал алдырып торучы
Тропик үрмә үсемлек

Өметбаев
Сунар
Ачулану
Россия шәһәре

Шайтан
Карта
Сулыклар төбендәге утырма
Дистә
Иделнең борынгы атамасы
Коры куак
Шулпа
«Любә» төркеме җыры
Гектар
Италия шәһәре
Диван
Солдатның хезмәт итү урыны

Фаил Гаязов төзеде

Горизонталь буенча: Гыймаева, Антарктида, НЛО, автор, аша, ни, саксофон, шифаханә, «Сарман», ал, Ева, лиф, асу, гривна, Тласкала, лиана, Раил, ләм, ку, иблис, Ра, ун, аш, Варезе, софа, армия.
Вертикаль буенча: Гаделша, Газиев, фани, Аллаиха, нәркиз, Алла, ау, Вена, Сайфуллина, Она, атлас, нюанс, «Ишо», Виолетта, акт, га, Осака, әр, Карина, Самара, ак, Муса, ул, абонент, Азалия.

МӘЗӘК БАБАЙ

Өлкәннәрнең барысы да аны бик хөрмәт итә. Ә без аны кайда очратсак та сырып алабыз да сөйләргә кушабыз. Ул бераз карышып торган була. Без сорыйбыз, үтенәбез, ялынабыз. Һәм, ниһаять, ризалаштырабыз. Юлыбызда очрамаса, аның эш урынына – каравылга барабыз. Сөйләтми туктамыйбыз. Ул сөйли, без тыңлыйбыз. Безгә кызык. Өлкәнрәк малайлар аны: «Бераз шыттыра», – дигән булалар. Дисәләр ни. Аның каравы, ул кызык итеп сөйли. Без көләбез. Һәм әчтән генә соңга калып тууыбыз, ул кичергәннәрне күрә алмавыбыз өчен бераз үкенәбез. Үкенерлек тә шул. Шулкадәр кызык сугышны күрә алмыйча калганбыз ич. Андый күңелле нәрсәләр әллә тагын була әле, әллә юк. Ә ул сөйли:

– Ә бер мәлне разведкага киттек. Биш кеше. Ап-ак киемнән. Кыш. Кар астына чумдык та йөзеп барабыз. Ике-өч чакрым узгач, башны күтәреп карасак, нимесләрне узып киткәнбез. Кире борылдык та тагы кар астына чумдык... Әй йөзәбез, малай, йөзәбез. Туктале дип калкып чыксак, кабат үзебезнекеләр янына кайтып җиткәнбез. Командир тәмәке тартып тора. Безне күрде дә бу тоз мылтыгыннан атып та җибәрде. Үзе тирги: «Болай аңгыраеп йөрсәгез, бер мидал да бирми өегезгә кайтарып җибәрәм. Барыгыз тиз генә тел алып кайтыгыз, яп-яланаяк малайлар», – ди. Кабат карга чумам гына дип торганда, яныбызда гына өч нимес калкып чыкты. Болар да разведкага тел алырга дип килгәннәр икән. Без аларны шундук борып салдык та командир алдына китереп куйдык. Әй шатланды командир моны күргәч, шундук ашханәгә җибәрде, суган шулпасы белән сыйланырга...

Без суган шулпасының нәрсә икәнен белмибез. Тик командир тиклем командир шуның белән сыйлагач, аны бик тәмле нәрсәдер дип уйлыйбыз. Өйгә кайткач, өлкәннәрне: «Суган шулпасы пешерегез әле», – дип йөдәтәбез. Алар пешерә. Итле аш шулпасына суган салып ясыйлар икән аны. Чынлап та тәмле була икән. И-и, монысын безнең әниләр генә пешерә ич аның, ә сугышта чын поварлар пешергәне тагы да тәмлерәктер инде. Кыш җитсә, карга чумып карыйбыз. Чумуы әллә ни кыен түгел, йөзеп кенә булмый.

– Бер мәлне, малай, атакага ташландык. Җиппәрәбез генә «Ура» кычкыра-кычкыра. Ике кешегә бер генә мылтык, аның да патроннары санаулы. Шулай булгач, йөгерергә җайлы. И без йөгерәбез. Окопларына килеп кенә җиттек дигәндә, нимесләр ата башлады. Ә без йөгерәбез, җиппәрәбез генә.

– Тидерә алмыйлармы сезгә? – дип сорый берәвебез.

– Тия инде, ничек тимәсен. Кораллары яхшы бит аларның, үзләре дә төз аталар.

– Тигәч, үлмисезмени?

– Үлдем дип кенә уйлап бетерәбез дә тагы терелә-без. Ул вакытта үзебез дә аңлап бетермәгәнбез инде, соңыннан гына белдек. Без үлемсез булганбыз икән. «Совет солдаты – үлемсез!» – дип әйттеләр соңыннан. Ярый, туктагыз әле, мин менә монда кереп чыгыйм әле... күзгә чүп кергән кебек булды...

Ул каравылчы йортының түр бүлмәсенә кереп китә. Мышкылдаган тавыш ишетелә, бераздан тамагын кырып ала. Һәм кабат безнең янга чыга. Елмая.

– Нәрсә, шилма малайлар, һаман китмәдегезмени әле?!

– Ә кулыңны кайда өздердең? – дип сорый берәвебез.

Без сискәнеп китәбез. Өлкәннәрнең болай дип сорарга ярамавын искәрткәннәре бар иде бит. Тик инде соң. Әмма аның исе дә китми.

– Өздермәдем. Үзе төшеп калган ул. Кеше күп иде, шуңа бик әзләп тә йөрмәдем инде. Җиңеллеккә болай җиңелрәк, канишны. Кайчагында уң колакны кашырга кирәк булып куя да... Ярый инде... Аны сул кул белән дә кашып була...

Бераз үсә төшкәч, без аның чынлап та шыттыруын аңладык. Һәм аның авызына карап мөкиббән киткән энекәшләребезне кисәтми кала алмадык: «Ышанмагыз, алдый ул». Алар, әлбәттә, безне тыңламадылар.

Ә тагы да зуррак үскәч, аның чынлап та орденлы каһарман икәнлеген белдек. Бик каты сугышка эләккән. Бөтен ротадан берүзе генә исән калган. Яралангач та, дошман белән алышудан туктамаган. Башта аны мәетләр белән бергә тезгәннәр. Соңыннан кемдер исән икәнлеген сизеп калган да медчастька озатканнар. Бу хакта ул үзе беркайчан да бер авыз сүз дә әйтмәгән. Кемдер сөйләгән. Ниндидер читтән килгән кеше. Һәм аңа ышанганнар. Хәер, үзенең дә азрак салып алган чакларында:

– Берүзем исән калдым бит. Берүзем... – дип аптырап та, әрнеп тә әйткәли торганы булган.

Һәм бетте шуның белән шул.

Бу вакыйгаларга инде бик күп еллар узды. Без дә олыгайдык. Аның белән бергә яуга киткән соңгы ветеранны җирләгәнгә дә унбиш ел үткәндер. Ә ул һаман исән. Хәзер инде хатирәләрен сөйләттерергә тырышып артыннан ияреп йөрүче малайлар да юк. Үзе дә сөйләргә бик атлыгып тормый. Тик шулай да кайбер чакларда үзен уратып алган башка заманга аптырабрак карап тора да:

– Берүзем исән калдым бит. Берүзем... – дип башын чайкап куя.

Марат КӘБИРОВ.

vk.com

Бөек сер

Туа кеше.
Озак яши кеше.
Үлә кеше серне аңламыйча.
Илаһи Көч Җирдә
йөртә аны
гомере буе һич тә
алдамыйча.
Алмаш туа аңа.
Яши.
Үлә.
Ул да китә.
Сере кала шулай.
Йөзенчесе,
меңенчесе серне
ачылмаган килеш
ала шулай.
Еллар үткән.
Мең еллар да үткән.
Миллион еллар шулай
үтәр тагын...
Ачылыр, дип Бөек
Яшәү Сере –
һәрбер кеше әле
көтәр тагын.
Шуңа күрә дә бит
Бөек Сер ул.
Бөек Сер ул һәрчак
читтә тора.
Кеше аңа якынайган саен,
шуның кадәр ул да
китә тора.
Ул ачылмас.
Ачылса да бары
ачылыр ул башка
затлар өчен.
Ачкычлары
галәм төпләренә
салынгандыр мәңге
саклар өчен.
Бер күкләргә карап
уйлау кызык,
уз-узеңне һич тә
алдамыйча.
Килгән китә!
Без дә бер китәрбез
үзебезне үзебез аңламыйча.
Яшәргә, дип кенә
тудырылган
Гомере бар
кеше яши генә.
Илаһи Көч Җирдә
йөртә аны,
алдамый ул –
бары дәшми генә.

Кадыйр СИБГАТУЛЛИН.

ТАШКА БАСКАН

✓ Тормыш турында күбрәк уйланган саен, уйлыйсы килми башлый.

* * *

✓ Бар да яхшы. Ләкин монда түгел.

* * *

✓ Хуҗасын саклый торган этләр дә, этен саклый торган хуҗалар да була.

* * *

✓ Тыелган нәрсә юк, мөмкин булмаганы гына бар.

* * *

✓ Төшегезгә татлы йокы керсен.

* * *

✓ Теләк тиз туа һәм бик акрын тормышка аша.

3 мәзәк

Хатын:

– Кадерлем, ә син белмисеңме, еланнар ничә яшькә кадәр яши икән?

Ир:

– Авырып торасыңмы әллә?

* * *

Ресторанда официант бер ир колагына иелеп сорый:

– Хатыныгыз нәрсә эчә?

– Минем каныммы!!!

* * *

Әйбәт кенә барган «Мерседес»ка «Москвич» килеп бәрелә. «Мерс»тан кызыл пинжәкле әзмәвер чыга һәм «Москвич» хуҗасы янына йөгереп килә:

– Имгәнмәдеңме? Аяк-кулларың исәнме? Бер җирең дә авыртмыймы?

«Москвич» хуҗасы, аптыраштa калып:

– Барысы да тәртиптә, рәхмәт.

Әзмәвер, җиңел сулап:

– Аллага шөкер! Алайса, әйдә, фатирыңны карарга киттек.

«ШӘҺРИ КАЗАН» – СИНЕҢ ӨЧЕН, СИНЕҢ ТУРЫНДА 8 (917) 851-69-62

ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)

www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ –
БАШ МӨХӘРРИР ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.

© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.

РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843) 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+
Сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 6043
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 710. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор) 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77-50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр - сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843) 562-50-12,
факс: (843) 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы